Түгәрәк үен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

3/ 2026



«Милли костюм – гади кием генә түгел, ул үткән белән бәйләнеш, ата-бабалар рухының чагылышы һәм үз-үзеңә килү юлы. Ул үзе бер серле китап кебек: аны ачкан саен халкыңның гореф-гадәтләре, йолалары һәм тарихы турында күбрәк беләсең»



Сез булсагыз – без үлемсез





«Уйнагыз, гармуннар!» фестивале елның-елында Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәре көне кысаларында узучы чараларның йөзек кашы булып тора. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләрне кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» ДБУ, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән берлектә оештырылган әлеге фестиваль быел 41 нче тапкыр узды. Анда Татарстанныкылар белән бергә Россиянең 21 төбәгеннән килгән меңнән артык гармунчылар, үзешчән сәнгать осталары, иҗат коллективлары катнашты.

Бәйрәм кунакларын, республика халкын һәм читтә яшәүче татарларны Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов исеменнән «Без – гармунлы, моңлы халык. Сәйдәшле, Илһамлы халык! Халкыбызның барлык матур сыйфатларын әлеге бәйрәм көзгедәге кебек ачып сала. Татар – моңлы, сәнгатьле, әдәбиятлы, бай, көчле рухлы халык, шуңа күрә аның киләчәгә дә, һичшиксез, бәхетле булачак», – дип, ТР Дәүләт Советы Рәисе вазифаларын башкаручы Марат Готыф улы Әхмәтов тәбрикләде.

Бәйрәм сәхнәсендә өлкән буын мәшһүр гармунчылар, җырчылар белән бергә, музыкаль мирасыбызны – халкыбызның милли моңнарын киләчәктә яңгыратачак 40 тан артык яшь музыкант – балалар һәм үсмерләрнең булуы аеруча куанычлы. Фестиваль тарихында беренче тапкыр быел Татарстанның биш районыннан килгән гармунчылар династияләре чыгыш ясады.

«Мәхәллә» иҗади киңлек проектында катнашкан һөнәрчеләр бизәкләрендә миллилек чәчрәп торган уникаль кул эшләнмәләрен тәкъдим итте.

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры каршысындагы мәйданнан «Туган тел», «Мин яратам сине, Татарстан» кебек телдән төшми торган җырларны җырлый-җырлый кузгалып киткән гармунчылар парадын Кабан күленең яр буйларыннан Г. Камал театрының амфитеатрына барып җиткәнче, шәһәр халкы, башкалабыз кунаклары сәламләде, бергә-бергә кушылып җырлады, биеде. Гармун моңы бер генә мизгелгә дә тынып тормады.

«Сез тынсагыз – без гомерсез, / Сез булсагыз – без үлемсез, / Туган моңнар, туган моңнар!» (Нәҗар Нәҗми) дип юкка гына язмаган шагыйрь.

«Уйнагыз, гармуннар!» фестивалендә катнашучы үзешчән сәнгать осталары һәм иҗат коллективлары белән берәттән бәйрәм чарасында Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле, «Казан» бию ансамбле, Татарстан Республикасы халык артистлары Гүзәл Уразова, Зәйнәб Фәрхетдинова, Рөстәм Асаев, Татарстанның атказанган артисты Сиринә Зәйнетдинова, популяр җырчы Ришат Фазлыйәхмәтовлар сәхнә тотты.

Чын мәгънәсендә «Уйнагыз, гармуннар!» – иртәдән кичкә кадәр дәвам итүче бер могҗиза ул. Иң сөендергәне дә шул: фестивальнең дәрәҗәсен халык үзе күтәрә.

Фотолар Бөтендөнья татар конгрессы сайтыннан алынды

ЭЧТӘЛЕК

ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ



4 **Россия халыкларының традицион костюмы. Ул нинди?**

8 **Һөнәрчелектән – сәнгатькә. Күнчеләр шул фикердә**

ЗӘВЫКЛЫЛЫК БЕЗДӘН БАШЛАНА



10 Э. Шәйхи **Тормыш стиле – мәдәни код**

КОЛЛЕКЦИОНЕР



20 Р. Фаизова **Нәсел самавырының хикмәте**

ӘДӘБИ МИРАС

26 Л. Мөхәммәтҗанова **Чичән сүзе бер булыр**

Түгәрәк уен

№3 (60) / 2026

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор:
Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир:
Расиха Габделбәр кызы Исмәгыйлова

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә (Роскомнадзор) ПИ № ФС77-79590 номеры белән теркәлгән.

Журнал өч айга бер чыга.
Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 17.09.2026 г.
Чыгу көне: 28.09.2026 г.
Заказ: № 221. Тираж: 1000 данә.

Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.

Г. Тукай

Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан, Тукай ур., 74 а.

Хатлар язар өчен адрес:
420015, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан, Пушкин ур., 66/33, тел.: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

Отпечатано в ИП Селиванова А.Г.
420015, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Галактионова, 14
тел.: +7(843)2382449
E-mail: Orange_k@list.ru

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

Тышлыкта: рәссам-дизайнер Ләйсән Хаҗиеваның «Зәбәрҗәт» тупланмасыннан (Казан)

© «Түгәрәк уен», 2026

МУЗЕЙЛАР БУЙЛАП



32 «Мин ант иттем җанны кызганмаска, Саклар өчен халкым, илемне...»

ИҖАТ ҺӘМ МАГИЯ

36 Г. Гыйльманов
Рухи кодларның, сихри тоем белән бәйле йолаларның иҗаттагы урыны


ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ БӘЙРӘМНӘРЕ



40 Р. Фаизова
Эх, сөлгесе – керсез күңел көзгесе

45 Г. Миннебаева
«Арча читекләре» милли мирас сагында

ОСТАЛЫК ДӘРЕСЕ



48 Г. Хәмзина
Каюлы күнне дөньяга танытып

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ



52 З. Зәйнуллина
«Изгеләр ашы»

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



56 И. Галиева, Г. Ихсанова
Күлмәк котлау

58 Э. Низамов, Р. Гобаева
Планеталар

ӨЙ КҮРКЕ – АШ



59 Г. Хәмзина
Карабодай бәлеше

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 Бергәләп бизибез!

Россия халыкларының традицион костюмы. Ул нинди?

4–6 сентябрьдә Казанда «Россия халыкларының традицион костюмы» Бөтенроссия фестиваль-конкурсы үтте. Мәдәни вакыйганы Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы ярдәме белән В.Д.Поленов исемендәге Россия халык иҗаты йорты, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләрне гамәлгә кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге оештырды.



Берничә урында узган чараларның программасы шактый колачлы булуы белән игътибарны җәлеп итте: милли костюм тупланмаларын подиумда күрсәтү; күргәзмә оештыру; экспертлар һәм белгечләр катнашында костюм традицияләре яссылыгында иҗади үсеш юлларын билгеләү, конкурска тәкъдим ителгән эшләргә җентекле анализ ясауга корылган конференция; кул эшләре ярминкәсе...

Пушкин мәдәни үзәгендәге ачылышта фестиваль кунакларын Татарстан Республикасының мәдәният министры Ирада Әюпова сәламләп, мондый масштаблы чараның Россия Федерациясендә беренче тапкыр узуын һәм фестиваль-конкурста 420 дән артык кеше катнашырга теләк белдерүен ассызыклады. «Глобализация шартларында без теге яки бу киемдә, асылда, нәрсәнең төп үзебезнеке, нәрсәнең читтән керүен бик еш кына онытабыз. Бу котылгысыз, бөтен нәрсә үзгәрә, әмма хәтта үзгәрешләрдә дә без үзебезнең эзне табарга бурычлыбыз. Теләсә нинди шартларда да нәрсәнең үзенә сак мөнәсәбәт һәм караш таләп итүче кыйммәтле орлык, кыйммәтле төш икәнен аңларга тиешбез, – дип белдерде ул. – Милли кием ул – безгә гасырлар төпкеленнән килгән тел, һәм ул теләсә кайсы этносның, теләсә кайсы милләтнең формалашуының барлык этапларын диярлек чагылдыра».







* * *

Фестиваль кысаларында Уникаль осталык үзәгендә оештырылган күргәзмә Россия Федерациясенең 24 төбәгеннән декоратив-гамәли сәнгать осталарын, кием дизайнерларын һәм иҗат коллективлары җитәкчеләрен берләштерде. Экспозициядә 200 дән артык курчак, 300 гә якын аксессуар һәм 20 костюм комплексы тәкъдим ителде. Конкурска тапшырылган эшләр биш номинациядә бәяләнде: «костюм аксессуарлары», «традицион костюмлы курчак», «этнографик костюм», «сәхнә костюмы», «заманча костюм».

Катнашучыларның географиясе Алтай Республикасыннан һәм Магаданнан алып Белгород өлкәсенә һәм Санкт-Петербургка кадәр булган территорияне үз эченә алды. Мәскәү, Рязань, Воронеж, Курган, Уфа, Таулы Алтай... Бу, һич арттырусыз, Россия халыкларының һәркайсы үз милли киеменнән чыккан бәйрәм парадын хәтерләтте.

Һәр почмагы мәхәббәт белән сугарылган әлеге күргәзмәне күрергә килүчеләр авторларга бары соклану катыш рәхмәт хисләре генә юлладылар: «Күптән мәхәббәтнең бу дәрәҗәдә бер урынга җыелуын күргән булмаган икән! Каз тәннәре чыкты.Үз куллары белән шундый матурлык тудыручылар алдында баш иям». «ЦУМдагы кыю үзгәрешләрне күреп күңел җиде кат күкләргә күтәрелер дәрәҗәгә җитте. Осталарның эшләренә килсәк – һәрберсенең үз стиле, күзаллавы, аерым детальләргә акцент ясау, сәнгатьчә бизәлеш шаккатмалы! Курчакларның йөз чалымнары, киемнәре үк аларның кайдан «килүләрен» әйтеп тора. Бер сүз белән әйтсәк – фантастика». «Ихластан яратып, күңел җылысын салып башкарылган эшләрне күргәч, балачакка кайткан кебек булдым, бугазга төер тыгылды, елыйсы килә хәтта».

* * *

Жюри әгъзасы, Дәүләт Эрмитажы белгече, сәнгать фәннәре кандидаты, Санкт-Петербург дәүләт сәнәгать технологияләр һәм дизайн университеты доценты Марина Алексеевна Блюмин да шушы рухи бердәмлек дулкынында иде. «Безнең өчен һәр халыкка хас булган милли гореф-гадәтләрнең, мәдәниятенең сакланууы бик мөһим. Бу күргәзмә менә шуны раслап тора: гореф-гадәтләр өйрәнелә, саклана һәм киләчәк буыннарга тапшырылачак», – дигән ышанычын һәм Казанның Россиядә бердәнбер булган Уникаль осталык үзәгенә соклануын белдерде ул да.

Биредә һәрнәрсә хаклы рәвештә үзенә игътибар таләп итә. Элеккеге физика-математика укытучысы





Сәгыйдә Янбердинаның (Башкортстан) 1939–1970 елгы фотографияләргә карап, реконструкцияләгән – сәйләннән үрелгән челтәре (күкрәкчә) һәм кашмау дип аталган баш киеме берәүне дә битараф калдырмагандыр. «Кызларыма да, киленемә дә шундый комплектлар эшләп бүләк иттем», – ди оста.

Флорид Вахитов (Башкортстан) исә, борынгы үрнәкләр нигезендә заманча технологияләр кулланып, традицион костюмнарны бизи торган ука (позумент) җитештерүне җайга салган.

«Тула костюмнары – минем өчен бер могҗиза. Аеруча хатын-кызларның баш киемнәренең («мөгезле кичка», «махрёна») ниндие генә юк!» – дип илһамланып эшләүче курчак остасы Надежда Черкасова, һөнәре буенча бухгалтер булса да, 26 ел буе күргәзмәләрдә катнашып килә икән. «Тулача киенәбез-ясанабыз» дип аталган тупланмасында ул музейларда, шәхси тупланмаларда күргән костюмнарны ничек бар шулай түкми-чәчми курчакларына кечерәйтеп эшли.

Наталья Магадиева (Киров өлкәсе) исә «Көньяк Нократ милли мәктәпләре балалары» тупланмасындагы курчакларына дигән күлмәклек тукымаларга кадәр этнографик үрнәкләр нигезендә үзе суккан булып чыкты. Рус, удмурт, керәшеннәрне чагылдырган эшен автор Россиядә Халыклар бердәмлеге елына багышлый.

Коми Республикасыннан килгән Тамара Хабарованы кем генә геолог дияр икән. Подольск машинасы белән традицион техникада мережкалап, челтәрләп тегелгән заманча күлмәкләрендә күл эшенең күләме 85 % лап булыр. «Бик чуар булмасын», – дип эшли торгач, өч күлмәкне эшләп чыгу ел ярымга сузылган.

Түбән Новгород шәһәрендәге «Параскева» кулланма-гамәли иҗат остаханәсе (җитәкчесе Ольга Бочарова) үзе генә дә бөтен конструкциясе – бармакларына кадәр гап-гади мунчаладан ясалган 20 традицион этнографик курчактан торган «Сормовоның олы юлы» тупланмасын тәкъдим итте. Темасы – яшь егетләрне Ватанны сакларга озату. Йоласы шулай: солдатка китәр алдыннан егетләр өй буенча йөреп саубуллашып чыгалар, ә икенче көнне бөтен авыл халкы, кешелеккә кия торган киемнәрен киеп, аларны озатырга чыга. Беренче карашка күңелле вакыйга, шул ук вакытта әниләрнең, сугыш үткән агайларның йөзендә әйтелмәгән моң-сагыш, борчу сизелеп тора. Тематик булу өстенә тупланма шул төбәк крестьяннарының XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына караган киемнәрен дә ачык чагылдыра.

Свердловск өлкәсенең Түбән Сырга районы Аракай авылы осталарының кигән киемнәре үк: «Безнең якларда



Фестиваль-конкурсны оештыручылар һәм жюри әгъзалары

чигә белми торган хатын-кыз юк », – дип тәкрарлый күк. Аларда килен мендәрләре, кияү кулъяулыклары, алъяпкычлар, күлмәкләр, өстәл япмалары – һәммәсе чигүле.

Традицион халык костюмы конкурсына тәкъдим ителгән эшләр, бер яктан, музей экспонатларын тирәнтен өйрәнеп, шуларга нигезләнеп, бөтен детальләре бөртекләп эшләнгән, тарихи реконструкцияләнгән костюмнар булуы белән җәлеп итсә, икенче яктан, буыннан-буынга килүче традицияләрнең, милли мотивларның заманча креатив яңгырашын күрү дә куанычлы. Аларның һәр икесе конкурсантларның гына түгел, фестиваль кунакларын да яңа идеяләргә этәрми калмагандыр.

Экспозициянең тап уртасында урын алган «Сахтиан» ҖЧҖ осталарының читекләрендәге, Лилия Галимуллина («Lusi» бренды) эшләнмәләрендәге «Казан җөе»нең серенә төшергә теләүчеләр дә шактый иде. «Этнографик костюм» номинациясенә тәкъдим ителгән XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Казанның Иске Татар бистәсе халкына – бу очракта традицион татар гаиләсенә хас костюмнар тупланмасы да игътибарны әллә каян җәлеп итә. Тупланманы башкарыр алдыннан тегү, җәйләрне эшкәртү технологияләрен өйрәнүгә, каптырмаларның үзенчәлегенә, файдаланылган тукымаларның, фурнитураның, киемнәрдәге функциональ чишелеш үзенчәлекләрен ачыклау буенча гаять зур эш башкарылган.

«Төп игътибарны өлгеләр алуга юнәлттек, чөнки әлеге киемнәрнең өлгеләре «Татарстан Республикасының Милли музее тупланмасында татар костюмы» («Татарский костюм в собрании Национального музея Республики Татарстан») китабына керде. Миңа калса, әлеге проектның төп табышы да шул, чөнки төгәл итеп алынган үлчәм ул безнең ата-бабаларыбызның гомерен озайтуга тиң», – ди әлеге тупланманы үз куллары белән башкарып чыккан дизайнер Элара Шәйхи («БЮРО БАНУ» бренды).

* * *

Конкурс жиңүчеләрен Казан Кирмәненең Туп утарында узган гала-концерт барышында бүләкләделәр. Җыеп кына әйткәндә, «Россия халыкларының традицион костюмы» Бөтенроссия конкурс-фестивале төбәкләрдәге осталарның профессиональ дәрәҗәсе югары булуын, халыкның милли мәдәният, милли тамырлар белән тирәнтен кызыксынуын күрсәтте. Иң мөһиме, фестиваль традицион костюмның бүген дә актуаль булып калуын һәм шул ук вакытта аның креатив индустрия тарафыннан яңа сулыш белән өретелеп заманча гардеробта урын алуын, көндәлек тормышта кулланылышта булуын дәлилләде.



Һөнәрчелектән – сәнгатькә. Күнчеләр шул фикердә

«Тормыш стиле – мәдәни код» V Халыкара этнофестивале быелгы җәйнең иң истә кала торган чараларының берсе булды. Аның Россиядә тиңе булмаган, республикада мәдәни мирасны саклауга хезмәт итүче Уникаль осталык үзәгендә узуы зур әһәмияткә ия.

Фестивальнең географиясе шактый колачлы, анда Россиянең 30 төбәгеннән һәм чит илләрдән (Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Һиндстан, Гыйрак, Катар, Маврикий, Марокко һ.б.) 300 дән артык дизайнер һәм оешма вәкилләре катнашты.

Әлеге масштаблы чара кысаларында Казанда беренче тапкыр «Һөнәрчелектән – сәнгатькә» дигән шигарь астында III Күн сәнгате фестивале эшләде. Моңа кадәр Мәскәүдә узган фестивальнең Татарстанга килүендә очраклылык юк, чөнки Казан – элек-электән үзенең тире эшкәртүчеләре, күнчеләре, сафьян читекләре белән дан тоткан җир.

Фестивальне ачу тантанасында катнашкан Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, фестивальнең максаты – хәзерге заман шартларында халык һөнәрчелеге үсешенең алдынгы тенденцияләрен күрсәтү, аны дөньяга таныту, дип ассызыклады һәм төбәкнең мәдәни тормышына керткән өлешләре өчен фестивальне оештыручыларга, анда катнашучыларга рәхмәтен белдерде.

Фестиваль эшендә Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Казахстан, Пятигорск, Чиләбе, Муром, Владимир кебек шәһәрләрдән (барлыгы 25 шәһәр!) килгән 80 нән артык оста катнашты. Фестиваль чыннан да тирене сәнгатьчә эшкәртүче танылган осталарны, рәссамнарны, бу өлкәдә элек-электән килгән бай тәҗрибәне киләчәк буыннарга тапшырырга әзер булган күнчеләрне үз тирәсенә җыйган.

Фестивальне оештыручы ассамбляж остасы, Россия һәм Евразиянең Кулланма-гамәли сәнгать рәссамнары иҗат берлегенең күн сәнгате гильдиясе җитәкчесе Андрей Коробейников үз чиратында һәрьяклап ярдәм күрсәткәннәре өчен Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюповага, Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләрне гамәлгә кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге җитәкчесе Алсу Мифтаховага һәм «Татарстан Республикасының креатив индустрияләрне үстерү үзәге» автоном коммерцияле булмаган оешманың генераль директоры Ранко Тепавчевичка рәхмәтле. Аның әйтүенчә, ике залда куелган 700 эш күннең нәзакәтлелеген, катлаулы техникалар аша (барельеф, гравюра, нәкышь, ассамбляж, басу, үрү, флористика)







сәнгати мөмкинлекләрен төрле яклап ачып бирә. Андрей Коробейниковның авторлык мәктәбе кысаларында узган тәҗрибә уртаклашулар, күргәзмә буйлап ясалган экскурсияләр – барысы да күн һәм аның затлылыгын тоеп эш итүче осталарның иҗаты турында иде. Күргәзмәгә килүчеләр декоратив-гамәли сәнгать осталары, рәссамнар уздырган төрледән-төрле осталык дәресләрендә дә бик теләп катнашты.

Казанлылар һәм шәһәр кунакларының уникаль үзәккә килгән күнчеләрнең уникаль эшләрен тиз генә җибәрәсе килмәве аңлашыла, шуңа күрә дә бер айга дип килгән күргәзмә 6 октябрьгә кадәр дәвам итте.









Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан



«ФАЩЭ» арт-лабораториясе
(Нальчик)



Элара ШӘЙХИ,
ТР Дизайнерлар берлегенең вице-президенты, «БЮРО БАНУ» брендына нигез салучы дизайнер

ТОРМЫШ СТИЛЕ – МӘДӘНИ КОД

22 – 26 ИЮЛЬДӘ МЕҢЬЕЛЛЫК ТАРИХЫ БУЛГАН КАЗАНЫБЫЗНЫҢ УНИКАЛЬ ОСТАЛЫК ҮЗӘГЕНДӘ (Мәскәү урамы, 2) ХАЛЫК ИЖАТЫ һӘМ ДЕКОРАТИВ-ГАМӘЛИ СӘНГАТЬКӘ БАГЫШЛАНГАН «ТОРМЫШ СТИЛЕ – МӘДӘНИ КОД» ДИП АТАЛГАН V ЭТНОФЕСТИВАЛЬ УЗДЫ. УЛ РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕННӘН һӘМ ЧИТ ИЛЛӘРДӘН КИЛГӘН ОСТАЛАР, һӨНӘРЧЕЛӘР, ДИЗАЙНЕРЛАР, МОДЕЛЬЕРЛАР, ШУЛАЙ УК ӘЛЕГЕ ЮНӘЛЕШТӘГЕ ӘЙДӘП БАРУЧЫ БЕЛГЕЧЛӘР һӘМ ТАРИХЧЫЛАР КАТНАШЫНДАГЫ ТӨБӘКАРА һӘМ ХАЛЫКАРА ДӘРӘҖӘДӘГЕ ӘһӘМИЯТЛЕ МӘЙДАНЧЫККА ӘВЕРЕЛДЕ.

Анда Россиянең 22 төбәгеннән һәм 10 чит илдән (Маврикий, Гыйрак, Нигерия, Катар, Төрекмәнстан, Кот-д'Ивуар, Гана, Марокко, Үзбәкстан, Кыргызстан) 300 дән артык халык сәнәгате һөнәрләре оешмалары, осталар, дизайнерлар һәм экспертлар катнашты. Биш көн дәвамында 30 меңгә якын казанлылар һәм шәһәребез кунаклары фестиваль чараларында катнашты. Этноподиум 3000 нән артык тамашачыны җәлеп итсә, эшлекле программалар 340 катнашучыны, шул исәптән 48 спикер һәм экспертны бер мәйданда очраштырды.

Чараның структурасы бер-берсе белән бәйләнгән берничә тематик блоктан гыйбарәт булып, аларның һәркайсы мәдәни мирасны саклау, үстерү һәм заманча күзаллауның аерым аспектларын (этномаркет, эш программасы һәм «Гореф-гадәт җепләре» этномода күрсәтү) ачты.

ЭТНОМАРКЕТ

«Тормыш стиле – мәдәни код» этномаркеты кунакларына традицион техникаларда башкарылган эшләнмәләрнең киң палитрасы: декоратив-гамәли сәнгать, текстиль, керамика, агач, күн һәм башка материаллардан җитештерелгән әйберләр, шулай ук дизайнерларның авторлык киемнәре һәм аксессуарлар тәкъдим ителде.



Маркетның әһәмияте продукцияне күрсәтүдә генә түгел, ә осталар белән турыдан-туры аралашуда иде. Фестиваль кунаклары эшләнмәләрнең барлыкка килү тарихы белән берәттән материалларның үзенчәлекләрен, бизәкләрнең ничек килеп чыгышын һәм технологияләрнең үзенчәлекле якларын белеп китте. Шуңа күрә этномаркет сату мәйданчыгы булудан гайре, мәдәни агарту һәм тере мәдәни диалог урынына әверелүе белән кыйммәт.

ЭШЛЕКЛЕ ПРОГРАММА

Эшлекле программа дүрт юнәлешне эченә алды: халык сәнгате һөнәрләре, этника һәм мода, креатив индустрияләр һәм күн сәнгате. Фикер алышуларда дизайнерлар, осталар, иҗади индустрия белгечләре, Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы вәкилләре, Халык сәнгате һөнәрләре буенча Федераль экспертлар советы, шулай ук Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре катнашты.

Төп игътибар тармакны үстерү, дәүләт ярдәме, заманча этнобрендларны формалаштыру һәм традицион бизәкләрне киемнәрдә һәм тирә-юньдә булдыру мәсьәләләренә юнәлтелде. Катнашучылар традицион технологияләрнең инновацион материаллар, цифрлы инструментлар һәм заманча брендинг принциплары белән ярашу-ярашмавын тикшерде. Аерым игътибар хәзерге базар шартларына яраклашу чорында мәдәни образларның үзенчәлеген саклау мәсьәләсенә бирелде.

ЭТНОПОДИУМ: «ГОРЕФ-ГАДӘТ ҖЕПЛӘРЕ»

Россия, якын һәм ерак чит илләрнең дизайнерлары катнашында узган этноподиум төп чараларның берсе иде. «Гореф-гадәт җепләре» дип аталды ул. Тупланмаларда милли костюм мотивлары, традицион бизәкләр, төрле халыкларга хас булган төсләр, символлар һәм сәнгать алымнары өстенлек итте.

Этник дизайнерның максаты – иҗат иткән тупланмасы аша тамашачыны үзенең мәдәни традицияләре белән таныштыру. Бу очракта эшнең мәгънәсе нинди материал, бизәк, төс, силуэт һәм башкару техникасы сайлавыңа

карап билгеләнә. Дизайнер традицион костюм элементларын кабатлап кына калмый, ә мәдәни мирасны үзенчә формалаштыра, ягъни үткәнгә мөрәҗәгать итеп, бүгенгене аңлый һәм традицияләр үсешенең киләчәктә мөмкин булган юлларын тәкъдим итә.

Нәкъ менә шунда «мәдәни код» төшенчәсенең мәгънәсе көн кебек ачыла. Ул символ-тамгаларда, образларда, орнамент-бизәкләрдә, төсләрдә, формаларда һәм сәнгати алымнарында чагылыш таба һәм нәкъ менә шулар аша мәдәниятне таныйлар һәм аңа заманча киңлектә яшәү мөмкинлеге бирелә.

Гана дизайнеры Фелиция Нана Адвоа Этруба Эссуман мәдәни кодны үзенчә аңлата: «Мәдәни код ул – минем килеп чыгышым, минем ышануларым һәм үз-үземне ничек итеп күрсәтүем. ETRUBAга нигез салучы – «баланы» аркасына асып йөрүче кеше буларак – мин мода аша үз мәдәниятемне, иҗадилыгымны, көчемне һәм башка берәүгә дә охшамаганлыгымны күрсәтәм».

«Паха тере» сәнгать һөнәрләре фабрикасы» ҖЧҖ генераль директоры Наталия Посынкина брендының үзенчәлеген чуваш чигүе һәм заманча эстетиканың берләшүе итеп карый: «Безнең үзенчәлек – гасырлар буе дәвам иткән чуваш чигүе белән заманча мегаполис эстетикасының симбиозы. Брендның үзәк символы-тамгасы булган көймә тормышның өзлексез хәрәкәтен һәм осталыкның дәвамчылыгын гәүдәләндерә. Без, кат-кат уйлап, бизәкләр ясыйбыз һәм әлеге «тере тылсым» заманча киемнең бер элементына әверелә».

Бу концепциядә бизәк декоратив функцияне генә башкарып калмый, ә символ-тамга буларак та хезмәт итә. Ул, тарих белән бәйләнешне саклау белән беррәттән, заманча яңгыраш та ала.

«Айбренд» (Башкортстан) дизайнеры Артур Искужин мәдәни кодны таныла торган тамгалар җыелмасы итеп күрә: «Мәдәни код ул – кешеләр үзләренекен таный, «укый» торган символлар җыелмасы. Минем очракта бу – бизәкләр, төсләр, алымнар һәм хәтта кәеф тә. Шәхсән миңа бизәкнең мәгънәсе матурлыгыннан мөһимрәк тә».

Мәскәүдән «Домотканый лён» брендының дизайнеры Татьяна Тювина өчен бизәк – рухи хезмәт нәтиҗәсе: «Бу сүзсез генә, тыныч кына пышылдаган дога кебек. Һәрбер бизәктә әз генә булса да көч һәм мәхәббәт саклана, ә оста кулындагы җеп аны үзенең нәсел-ыруы, туган җире, тормышның үзе белән бәйли».

«Хан кызы» (Башкортстан) брендының дизайнеры Гөлсем Хөсәенова, милли костюмның әһәмиятен тарихи хәтернең бер чагылышы буларак ассызыклый: «Милли костюм – гади кием генә түгел, ул үткән белән бәйләнеш, ата-бабалар рухының чагылышы һәм үз-үзеңә килү юлы. Ул үзе бер серле китап кебек, аны ачкан саен халкыңның гореф-гадәтләре, йолалары һәм тарихы турында күбрәк беләсең».

Казандагы «Кокон» иҗади лабораториясе җитәкчесе, төрки халыкларның традицион мәдәниятен өйрәнүче Римма Кашапованың «Сәүдәгәр» тупланмасы татар халкының тарихи үткәне белән тоташтыра. Анда татар сәүдәгәрләре – сәүдә эшенә юл яручыларның образлары, Нәкшбәнд суфи ордены белән бәйле рухи традицияләр чагылыш тапкан. Беренчесе Казан территориясендә киң таралган һөнәрләр, традицион костюм һәм өйдәге яшәеш белән бәйле булса, икенчесе бүгенге көнне чагылдырды: традицион элементлар, минималь силуэтлар заманча конструктив чишелешләр белән ярашып килгәнлектән милли мирасны танып була һәм ул мода дөньясында актуаль.

Татарстан Республикасы Дизайнерлар берлеге исә ике дәверне очраштырган «Осталар шәһәрчеге» тупланмасын тәкъдим итте. Беренчесе Казан территориясендәге һөнәрчелек белән бәйле өйдә кия торган традицион костюм булса, икенчесе традицион элементларның минималистик силуэтлар белән яраклашып заманча конструктив чишелешле булуы белән игътибарны җәлеп итте. Шуңа күрә дә милли мирасны танып була, һәм ул мода дөньясында актуаль.

СӘНГАТЬЧӘ ЯКЫН КИЛҮ ҺӘМ ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ КҮРСӘТҮ АЛЫМНАРЫ

Этноподиум сәнгатьчә якын килүнең төрлелеген күрсәтте. Дизайнерлар театральләштерүгә, фольклор сюжетларга, экологик материалларга һәм цифрлы технологияләргә мөрәҗәгать итә. Этник мода бу очракта үзен дизайн, театр, декоратив-гамәли сәнгать һәм мәдәни хәтерне өйрәнүче күренеш буларак танытты.

Пензадан Халык мода үрнәк театрына нигез салучы сәнгать җитәкчесе, дизайнеры һәм режиссёры буларак Ольга Букина әкиятне заманча этника теле буларак куллана. Ул тәкъдим иткән «Вакыт елгасы» тупланмасы – үткән заман белән бүгенгенең һәм киләчәкнең үзара бәйләнеше хакында. Театраль бирелеш костюмны сюжет, музыка, яктылык һәм сәхнә хәрәкәтләре аша ача.

Красноярск дизайнеры Елена Павлюкова (Element Soul бренды) ут, җир, су һәм һава образларына мөрәҗәгать итә. Аның концепциясендә табигый минераллар һәм ташка әверелгән әйберләр көмеш белән чагыштырыла. Шул рәвешле табигатьнең нечкәлеге белән индустрия дөньясының катылыгы арасындагы үзара бәйләнеш чагылдырыла.

«Феникс» бренды дизайнеры Юлия Котова, (Коми Республикасы) төньяк табигатен традицион бизәкләр һәм заманча технологияләр белән берләштергән. Урман күтәренке рухлы урын буларак кабул ителә, ул мифологик тамашалар һәм ата-баба образлары белән бәйле. Тупланмада табигый тукымалар, кул эшләре, акварель бизәкләр, традицион орнаментика һәм цифрлы басма кулланыла.

МОДА – ДИАЛОГ КОРАЛЫ

Этник мода – яңа кием тәкъдим итү генә түгел, ә традицион кыйммәтләрне, мәдәни күптөрлелекне һәм халыклар арасындагы дуслыкны пропагандалау коралы да. Костюм билгеле бер мәдәниятнең тарихы, дөньяга карашы һәм зәвыгы турында сөйли. Визуаль образ тел каршылыкларын һәм географик чикләрне үтәргә сәләтле.

Катардан килгән Aadima брендының дизайнеры Манджулакшми Бхаратан әйтүенә караганда, «Мәдәни код ул – теге яки бу илнең мода һәм этник моданың әһәмияте турындагы диалогы. Аны үстерү аша яңа «әфлисун төсендәге икътисадны» тудырырга мөмкин. «Мәдәни код» фестивале – Татарстанның күркәм концепциясе һәм инициативасы: ул үз мәдәниятен дөнья-күләм мәйданга чыгара һәм мәдәни мода, аның кыйммәтләре турында хәбәр җиткереп, мәдәни брендларны үзенә кушылырга чакыра».

Яшь дизайнерларга ярдәм күрсәтү фестивальнең мөһим миссиясе булып тора. Профессионаллар очрашкан чарада катнашу яшьләргә тупланмаларын күрсәтү, сәнгать индустриясе вәкилләре белән элемтәләр урнаштыру мөмкинлеге бирә.

Сочидан Казанга бишенче ел рәттән килүче 17 яшьлек дизайнер Софья Терешинаның (бренд Sofya Tereshina) тупланмасы балалар һәм үсмерләргә багышлана. Аның заманча модельләрендә табигый тукымалар славян символикасы белән очраша. Яшь булуына карамастан, Софьяның иҗади концепциясендә мәдәни мирасның әһәмияте турында төпле караш формалашып өлгергән күзәтәбез. «Мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез саклансын, балаларыбыз, үсмерләребез өчен ул чит-ят булмасын иде», – ди дизайнер.

МӘДӘНИЯТЛӘРНЕҢ УРТАК СЫЙФАТЛАРЫ

Фестиваль төрле халыкларның мәдәниятләренә, гореф-гадәтләренә хас уртак сыйфатларны (өлкәннәргә хөрмәт, кул эше тотуның мәгънәсе, табигать белән бәйләнеш, кием-салымны социаль һәм рухи мәгълүмат җиткерүче буларак кабул итү һ.б.) ачыкларга ярдәм итте.

Кыргызстаннан килгән «Кызыл бизәк» брендының дизайнеры Татьяна Воротникова кыргыз һәм татар халкының озын күлмәк, киң чалбар, чигүле камзул, изү, билбаулардагы һәм баш киемнәрендәге охшашлыкларны билгеләп үтте. Бу шулай ук катлы-катлы киенү принцибында да күзәтелә.

Наталия Посынкина да мәдәниятләрнең берләштерү потенциалын ассызыклый: «Мәдәният – берсүзсез бердәмлек мәйданы. Һәрбер милли үзенчәлекнең үз уникальлеге булса да, чуваш һәм татар халыкларын ата-бабалар мирасына тирән хөрмәт, хезмәт сөючәнлек һәм декоратив-гамәли сәнгатькә изге итеп карау якынайта».

ШӘҺӘР МӘДӘНИ ТЕКСТ БУЛАРАК

Мәдәни код төшенчәсе кием-салым һәм орнамент белән генә түгел, шәһәр мохите белән бәйләнергә дә мөмкин. Шәһәр үз чиратында тарих, архитектура, көндәлек мәшәкатьләр, аш-су, һөнәрчелек һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр чагылышы булган катлаулы мәдәни текст.



«Кызыл бизәк» бренды
(Казахстан)



Екатерина Ребежа
(Мәскәү)



«Кокон» иҗади
лабораториясе
(Казан)



«Этруба» бренды
(Гана)

ГАНА ДИЗАЙНЕРЫ ФЕЛИЦИЯ НАНА АДВОА ЭТРУБА ЭССУМАН

МӘДӘНИ КОДНЫ ҮЗЕНЧӘ АҢЛАТА: «МӘДӘНИ КОД УЛ – МИНЕМ КИЛЕП ЧЫГЫШЫМ, МИНЕМ ЫШАНУЛАРЫМ һӘМ ҮЗ-ҮЗЕМНЕ НИЧЕК ИТЕП КҮРСӘТҮЕМ. ETRUBAГА НИГЕЗ САЛУЧЫ – «БАЛАНЫ» АРКАСЫНА АСЫП ЙӨРҮЧЕ КЕШЕ БУЛАРАК – МИН МОДА АША ҮЗ МӘДӘНИЯТЕМНЕ, ИҖАДИЛЫГЫМНЫ, КӨЧЕМНЕ һӘМ БАШКА БЕРӘҮГӘ ДӘ ОХШАМАГАНЛЫГЫМНЫ КҮРСӘТӘМ»



«Aadima» бренды
(Катар)



«OMINO» бренды
(Нигерия)



Халык мода үрнәк театры
(Пенза)



«Хан кызы»
(Башкортостан)

«ХАН КЫЗЫ» БРЕНДЫНЫҢ ДИЗАЙНЕРЫ ГӨЛСЕМ ХӨСӘЕНОВА: *«МИЛЛИ КОСТЮМ – ГАДИ КИЕМ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, УЛ ҮТКӘН БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШ, АТА-БАБАЛАР РУХЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ һӘМ ҮЗ-ҮЗЕҢӘ КИЛҮ ЮЛЫ. УЛ ҮЗЕ БЕР СЕРЛЕ КИТАП КЕБЕК, АНЫ АЧКАН САЕН ХАЛКЫҢНЫҢ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕ, ЙОЛАЛАРЫ һӘМ ТАРИХЫ ТУРЫНДА КҮБРӘК БЕЛӘСЕҢ»*



(SILKVATS бренды
(Үзбәкстан)



Nailya Borhan бренды
(Казан)



InfinityBee бренды
(Мавритания)



Мода йорты
(Гыйрак)



«NAIMAN» бренды
Дизайнер: Галия Измаилова
(Казан)



«WIN-WIN LARE» бренды
Дизайнер Киселева Наталья
(Казан)



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДИЗАЙНЕРЛАР БЕРЛЕГЕ ИСӘ ИКЕ ДӘВЕРНЕ ОЧРАШТЫРГАН «ОСТАЛАР ШӘһӘРЧЕГЕ» ТУПЛАНМАСЫН ТӘКЪДИМ ИТТЕ

Мавританиядән килгән InfinityBee брендының дизайнеры доктор Самира Чаттун Койратты исә: «Казанга килгәндә, мин шуны аңладым: мәдәният урамнарда, һөнәрләрдә, кунакчыллыкта. Шул ук вакытта ул кичке шәһәргә ямь биреп торса, мирасыбыз яши дигән сүз».

«ФАЩЭ» арт-лабораториясе дизайнеры Жанна Битокова да (Нальчик) Казанда алган тәэсирләре белән уртаклашты: «Казан миңа төрле мәдәниятләрнең һәм дәверләрнең тыныч һәм табигый рәвештә бергә яшәве белән гажәпләндерде, әйтерсең шәһәр, күптөрлелекне һәм бердәмлекне күрсәтер өчен, махсус төзелгән диярсең».

ЯҢА ИДЕЯЛӘР ҺӘМ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

Фестивальнең халыкара форматта узуы тәҗрибә уртаклашу һәм яңа проектлар барлыкка килү өчен шартлар тудырды.

Дизайнер Оносохво Огенемине (Нигерия. OMINO бренды) Казанда Африка модасын халыкара аудиториягә тәкъдим итәрлек яңа идеяләр барлыкка килүен һәм үз йөзеңне саклап калган хәлдә, төрле мәдәниятләрнең йогынтысын берләштерү мөмкинлекләрен күрүен белдерде.

Үзбәкстан дизайнеры Пулат Юлдашев (SILKVATS бренды) ике мәдәниятнең визуаль диалогын төзергә, әйтик, заманча текстильдә Үзбәкстанның үсемлек орнаментын татар мотивлары белән берләштереп карарга тәкъдим итте. Монда иң мөһиме – турыдан-туры күчерү түгел, ә уртак пластиканы эзләү һәм яңа сәнгати чишелеш табу.

«Кокон» иҗат лабораториясе җитәкчесе Римма Кашапованың тупланмасы шундый хезмәттәшлеккә мисал булып тора. Алар Маргилан осталары тарафыннан традицион абрбанд техникасында эшләнгән «Татар икаты» ефәк тукымасын кулланып тегелгән. Шул рәвешле үзбәк технологиясе татар сәнгате контекстында чагылыш тапты һәм ул төрле һөнәрчелек культураларының үз үзенчәлекләрен саклаган хәлдә хезмәттәшлек итү мөмкинлеген күрсәтте.

Бу очракта коллаборация – эшлекле хезмәттәшлек кенә түгел, ә мәдәни диалог механизмы да. Төрле тәҗрибә һәм профессиональ күнекмәләргә ия белгечләрнең уртак хезмәттәшлеге традицион алымнарны заманча дизайнер чишелешләре белән баетырга, халык һөнәрчелегенең кулланыш даирәсен киңәйтергә һәм җәмгыятьнең милли мәдәниятка карата кызыксынуын арттыру мөмкинлеген бирә.

Nailya Borhan брендының дизайнеры һәм Казан дәүләт мәдәният институты аспиранты Наилә Борһанова фикеренчә, «Мода ул – төрле мәдәният вәкилләренә дә аңлаешлы универсаль тел». Наилә киләчәктә дә милли мирас заманча сәнгать һәм дизайнның нигезе булып торуын күрсәтүче халыкара проектларда катнашырга теләвен белдерде.

Казан халык сәнгате һөнәрләре техникумы директоры Раушания Сәүбановага җитештерү технологиясен кешедән сорыйсы түгел. Башыннан ахырына кадәр бөтен этабы аның күз алдында: һөнәрче оста технологияне саклый, дизайнер аны заманча таләпләргә яраклаштыра, ә җитештерүче масштаблаштыру һәм таныту өчен шартлар тудыра. Нәтиҗәдә милли мирас, музей даирәсендә генә калмыйча, мода һәм креатив индустрияләр мәйданында яшәвен дәвам итә.

ФЕСТИВАЛЬНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ

Фестиваль Татарстан Республикасы җитәкчелеге, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге, Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы ярдәме белән узды.

Чараның мөһимлеген беренче чиратта тамашачылар – аудитория бәяли һәм алар безнең киләчәктәге эшчәнлеккә юнәлеш күрсәтүче буларак хезмәт итә.

Фестиваль гореф-гадәтләрне заман күзлеге аша карап аңлаганда, аны саклап калу мөмкинлеген күрсәтте. Милли костюм, милли бизәкләр, һөнәри технологияләр һәм халык сәнгате һөнәрчелеге мода, дизайн, театр һәм цифрлы эш кораллары белән үзара бәйләнештә булып үсешен дәвам итә. Үткән заман бүгенгегә каршы куелмый, ә яңа сәнгать чишелешләре, профессиональ багланышлар һәм халыкара мәдәни диалог өчен нигез булып хезмәт итә.

Д. Бабушкин, Д. Петреченко, Р. Фаизова фотолары

НӘСЕЛ **САМАВЫРЫНЫҢ** ХИКМӘТЕ



Расиха ФАИЗОВА

Казанда ЦУМга, ягъни Уникаль осталык үзәгенә аяк баскан кеше коллекционер Рөстәм Миңнегали улы Әхмәтҗанов тупланмасындагы самавырларны күрми китмидер, мөгаен. Биредә ул тупланмасындагы 600 самавырның нибары 200ен генә тәкъдим итә дисәк, бу шөгыльнең шактый җитди булуын һәм кичә-бүген генә башланмавын чамалавы кыен түгел. Арада үзебездә җитештерелгәннәре дә, читтән кергәннәре дә, шул исәптән «мин» дип әллә каян ук үзенә дәшкән көязләре дә, «затлы чыгышлары» белән җәлеп иткән мөһерлеләре, уникаль конструкциягә ия патентлылары да, тыйнаграк, әмма башка сыймаслык тарихлылары да байтак. Кыскасы, аларны башка коллекционерларны да көнләштererлек, яки гаҗәеп дизайнлы дип кенә түгел, ә ил тарихының бер сәхифәсе, көндәлек тормышыбызның, милли гореф-гадәтләребезнең алыштыргысыз бер өлеше буларак карау да мөһим. Шундый тупланмасы булган кешенең гаиләсе һәр иртәдә самавыр кайнаган тавышка уянадыр, дип уйласагыз ялгышасыз. Эшмәкәр кешенең, элеккеге самавырларга күмер салып, чыра телеп утырырга әллә ни вакыты да юктыр. Шулай да җәмәгате Венера ханымның туган ягы булган Сарман якларына – Сөлек авылына кайткач, туган-тумача белән 6–7 гаилә бер булып чишмә буена төшкәндә, ул, һичшиксез, 16–18 литр сыешлы самавырын үзеннән калдырмый. Ничек инде Бакыр базы чишмәсенә куна төш тә, самавырың да булмасын имеш...



Банка-үрмәкүч.
Җитештерүчесе: Николай Иванович Баташев.
Россия империясе, Тула, 1880 еллар. Үлчәме: 43x33. Күләме: 6 л


Чашей, орешком с ажурными/византийскими ручками
Производитель: Ижевский Бутковка Российская империя, 2-ая полов. XX веков
Материал: латунь, дерево, клеймо, чугун
Размер: 46,00 см
Объем: 4 л
Банка с поясом, жёрудь с ажурными/византийскими ручками

САМАВЫР КУЙДЫМ КҮМЕРСЕЗ, КАЙНАП ЧЫГАР КҮРЕРСЕЗ

– Рөстәм әфәнде, соңгы вакытта Сез үз тупланмагызны шәһәр халкына гына түгел, ә ил күләмендә узучы зур-зур халыкара чараларда да тәкъдим итәсез. Нинди хисләр кичерәсез мондый чакларда? Нинди фикер-тәкъдимнәр ишетәсез?

– Эшләгән эшнең нәтиҗәсе булу, аны югары даирәләрдә, бер үк вакытта чит ил делегацияләренә күрсәтү, әлбәттә, горурлык хисе тудыра. Билгеле, сокланып, самавыр җитештерү тарихына төшенергә, аңларга тырышып карыйлар. Экспозицияне күпме кеше карый, барысы да яхшы кәеф белән китә. «Берүк, бу тупланма чит-ят җирләргә, кыйтгаларга китә күрмәсен, үзебезнең казаныш буларак республикада калсын», – диючеләр дә; «Тупланмагызның киләчәгән ничегрәк күзаллыйсыз, сатып җибәрмисезме?» – дип тел төбен чишәргә азапланучылар да юк түгел. Саткан очракта да мин аны кабат җыя алыр идем сыман, чөнки кайсысын каян алырга икәнен инде белеп эш итәчәкмен. Әмма шул үк вакытта киләчәк буыннарга, оныкларыма нинди дер рухи мирас калдыру турында да уйланам.

– Бу шөгылегез нигезсез түгеллеге күренеп тора, чөнки экспозициянең иң түрендә Сезнең өчен иң кыйммәтле экспонатларның берсен – нәселдән-нәселгә күчкән, ягъни Әхмәтҗановлар самавырын күрәбез. Аның тарихы ничегрәк? Коллекционер булып китүегездә аның йогынтысы ни дәрәҗәдә?

– Ул – 10 литрлы Баташев самавыры. Аны миңа моннан 20 еллар элек туганыбыз Сәлимә апа: «Менә, улым, сиңа үзебезнең Әхмәтҗаннар нәселенең самавырын ышанып тапшырам»,– дип биргән иде. Ул вакытта әле бу эш белән шөгыльләнү минем төшемә дә кергән нәрсә түгел. Хәзерге акылым булса, каян алынган, кайчан, ничек безгә килеп кергән, дип аның тарихын да сораштырган булыр идем. Ул вакытта игътибар бирелмәгән, хәзер инде сораштырыр кеше дә юк. 2012 елны шәхси йорт сатып алгач, дизайн өчен дип кенә унлап самавыр сатып алган идем. Ничектер шул вакытта үзеннән-үзе коллекционерлар белән аралашу башланды, кызыксынып киттем. Тора-бара самавырлар саны артты. Түбән Новгород өлкәсендә Андрей исемле дустым бар. Ул: «Рөстәм, әйдә, самавыр музее ач», – дип, еллар дәвамында гел үгетли килде. Соңгы вакытта ЦУМда – Уникаль осталык үзәгендә төшергән видеоларны җибәрдем үзенә. «Менә бит минем күптәнге хыялымны тормышка ашыргансың! Афәрин!» – дип язды.

Музей димәктән, үземдә дә андый уй юк түгел иде. Күп кенә музейларда, әйтик, Тулада «Тула самавырлары» музеен, Касыйм шәһәрендә «Рус самавыры» шәхси музеен кызыксынып карадым.

– Быел татарның бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел. Татарстанда 2026 ел Габдулла Тукай елы дип игълан ителде. Сез аны үзегезчә билгеләп узарга булгансыз икән.

– Әйе, революциягә кадәр чыккан 150 еллык Баташев самавырына гравировка белән Г. Тукайның сурәтен ясаттым һәм «Туган тел» шигырен яздырдым. Аны ювелирлар остаханәсендә башкардылар. Хәзер ул минем өчен генә түгел, һәр татар өчен кыйммәтле экспонатка әверелде.

– Сезнең күз төшәрлек самавыр ул кайсы ягы белән җәлеп итәргә тиеш? Борынгылыгы, чыгышы, формасы – кыяфәте белән, яки нинди металлдан булуы кыйммәтме?



Шар-үрмәкүч.
Иран. XXI гасыр. Үлчәме: 40х40. Күләме: 3 л



Йөзем тәлгәшле ваза.
Җитештерүчесе: Николай Савельевич Славянов.
Россия империясе, Мәскәү, XIX гасыр уртасы.
Үлчәме: 42x30. Күләме: 3 л



Тәпән.
Җитештерүчесе: Шеко остаханәсе.
Сынчы Наталья Мавринская. Россия Федерациясе,
Таганрог, XXI гасыр. Үлчәме: 45x36. Күләме: 7 л

– Билгеле беренче чиратта борынгыракка, бүгенге көндә сирәгрәк очрый торганнарга игътибар итәсең. Самавырның кыяфәтләре төрле, аларның миндә «ваза», «ярымваза», «мичкә», «пуля», «рюмка», «карбыз», «шар» рәвешендәгеләр генә түгел, революциягә кадәр җитештерелгән бер үк вакытта өстәл лампасы ролен үти торганы да, кофейник, бал тәпәне, тавык тәпиле ызба итеп ясалганы һәм хәтта койрыгы белән керосин савытын, ә зәһәр теле белән кайнап утырган чәйникне күтәреп торучы сихри кош рәвешендәгеләре дә бар. Трактирларга хас ике борынлы самавыр да кызыксыну уятмый калмый.

Шәхсән үземә ваза рәвешендә булып тәпиләренә йөзем агачы сарылып «үскән» (Н.С. Славянов, Мәскәү, XIX гасыр уртасы); үрмәкүч пәрәвезе шикелле тоткычлар, тәпиләр куеп эшләнгән (Н.И. Баташев, 1880, Тула), банка сыман самавырларым бик кадерле.

Чимал ягыннан карасак, алар төрле – мельхиор, җиз, чуен, бронзадан (бакыр белән кургаш эретмәсе) яки җиз белән цинкны кушып ясалган томпактан булырга мөмкин. Чиста көмештән эшләнгәннәре дә очрый. Мисал өчен, Николай II нең балалары – дүрт кызы һәм бер улы өчен бер чынаяк чәй сыярлык кына итеп ясалган көмеш



Кырлы касә.
Җитештерүчесе: Николай Николаевич Маликов. Россия Империясе, Тула. 1850–1882. Үлчәме: 40х44. Күләме: 10 л

самавырлары булган. Халык телендә мондый самавырларны «эгоист» дип тә йөртәләр.

Минем тупланмада иң борынгы дигән самавыр 1740–1760 елларга карый. Бездә, әйтик, Уралда Демидов заводында эшләнгән самавырларның баштарак бөтенләй дә борыны булмаган. Ул берничә бүлектән булып, кайсысында ботка, кайсысында үлән чәе кайнатканнар.

– Моның белән Сез самавырның заманчаларының бик кызыксындырмый диясегез киләме?

– Юк. Алай диярга җыенмыйм, чөнки бүгенге җитештерүчеләрдә дә хәтта революциягә кадәр бик хасиятләп эшләнгән самавырлардан да затлыраклары очрап куйгалый. Әйтик, Әрмәнстандагы дусларым Иранннан шундый затлы, җитмәсә, бердәнбер данәдә эшләнгән самавырлар алып кайта.

ХӘРБИ ТРОФЕЙ ИЛЕБЕЗГӘ КИРЕ КАЙТТЫ

– Самавыр нинди генә булмасын, яңамы ул, борынгымы – аның бер мистик сыйфаты бар: ул табын түрендә утырса, күңелгә үзеннән-үзе җылылык иңә. Без әле элгәре әбиләрнең иртәнге чәйгә дип самавыр эченә тезеп йомырка пешергәннәрен дә хәтерлибез. Сезнең тупланманы күргәч, каян табып бетермәк кирәк бу кадәр самавырны диюләре бәхәссез. Бөтенесе үзенчәлекле, затлы, җитмәсә берсе дә бушка килмәгәндер. Арада аяклы тарих буларак, үз кыйссасы белән килеп кергәннәре күпме?

– Дөрес әйтәсез, дөнья буйлап (Германия, Франция, АКШ, Австралия, Бөекбритания, Англия, Иран, Голландия, Казахстан, Үзбәкстан, Дагстан, Әрмәнстан һ.б.) җыелган тупланма икәнен дә искәртсәм, шактый чыгымлы шөгыль булуы шик калдырмый. Хәер, самавыр элек тә очсыз булмаган. Сыерлата да, атлата да түләгәннәр кулга төшерер өчен. Әлбәттә, аларның һәркайсының нинди дә булса тарихы бар. Әйтик, күбесе турында кайда җитештерелүе, нинди күргәзмәләрдә урыннар яулавы турында әйтергә мөмкин. Арада Идел буендагы ачлык чорында 1927 елда бер пот онга алмашу бәрабәренә хуҗасын үлем тырнагыннан йолып калганы да бар. Дәресрәге, Түбән Кама районының Ширмәт авылы кешесен, аның гаиләсен әлеге 16 килограмм он ачлык афәтеннән исән алып калгандыр дип бик өметләнәсе

килә. Алыш-бирешнең Болгар авылында булуы да мәгълүм. Сүз мәшһүр фабрикант Николай Маликовның томпак самавыры турында бара. Ул миңа кулдан-кулга күчә-күчә Түбән Камада килеп керде. Моннан ун ел элек без аны антик форумга (антиквариат һәм коллекционерлар өчен интернет форум) куйдык. Америкада яшәүче коллекционер Игорь Манако: «Мондый самавырны нибары өчне беләм. Икесе синең белән миндә, өченчесе Украинада», – дигән иде. Миндә Н. Маликовның 15–20 ләп томпак самавыры бар. Аларның үзенчәлеге шунда: алар алтын кебек ялтырап торалар.

Германиядә яшәүче Равия апам интернет аша хуҗасы белән элемтәгә кереп, миңа дип юллап алган самавырның тарихы шактый гыйбрәтле булып чыкты. Россиягә китәчәген белгәч, сатучы карт Польшада эшләнгән әлеге самавырның үзләренә ничек килеп эләгү тарихын да сөйләп бирә. Баксаң, Икенче бөтендөнья сугышында катнашкан бабасы аны Германиягә сугыш трофее (!) буларак Советлар Союзыннан алып киткән булган. Бер караганда, кем өчендер ул 5–6 килограммлы металл булып күренергә дә мөмкин, ә төптән уйлаганда бу бит тарих. Ул самавырның кире үзебезгә кайтуына мин ихластан сөенәм. Ул үзе ваза рәвешендә (51х36 см) 5 литр су сыешлы, һәм аны керосинга да, күмергә дә көйләргә була.



Күмерле-керосинлы ваза.
Сугыш трофее. Җитештерүчесе: билгесез.
Россия империясе, Польша патшалыгы. XIX гасыр ахыры.
Үлчәме: 51х36. Күләме: 5 л

Әле төпченеп, тарихының төбенә төшәсе килгән самавырларым да бар. Моннан элек Юлия исемле кыз Казан химиклар мәктәбенә нигез салган Александр Михайлович Бутлеров яшәгән Бутлеровка авылында (Казан губернасының Спас уезды, хәзерге Алексеевск районы) гомер иткән әбисенең самавырын китерде. Номер сугылган самавыр! Ә номерны 100 самавырның унысына гына, иң яхшыларына гына суга торган булганнар. Ул һич кенә дә гади кешедә була торган нәрсә түгел. Беренче чиратта шуның элеккеге хуҗалары кем булуын ачыклыйсым килә.

– Фәлән кг металл дигәннән, самавырны элек үлчәүгә салып, килограммлап та сатканнар бит әле. Сездәге иң зур самавырлар турында да беләсе килә.

– Хәйләсез дөнья файдасыз, диләр бит, элек осталар шундый хәйләгә бара – самавыр авыр килсен дип аның көл төшә торган колосник дигән җиренә күпләп чуен агыза торган булганнар. Минем тупланмада иң зур дигән самавыр 50 литр су сыйдырышлы.

– Сез бу шөгыльгә фәнни якын килеп, инде шактый саллы, мәгълүматлы каталог – альбом да чыгарырга өлгергәнсез икән.

– Әйе. Аны тарих фәннәре кандидаты Рәмис Рөстәм улы Мөхәммәтшин һәм фотограф мәрхүм Равил Әдһәм улы Кәримов белән бергәләп эшләдек. 430 биттән торган альбомга 250 ләп самавыр һәм алар турында белешмә керде. Кызыксынган кешегә бу – чыннан да үзенә күрә энциклопедиягә тиң басма.

– 600 самавыр иясенең нинди уй-хыяллар белән яшәвен дә беләсе килә.

– Самавыры булгач, аның хуш исле үләннәр салып тәнәтелгән чәе дә булырга тиеш билгеле. Безнең татар халкының ул инде канына сеңгән әйбер: килгән кунагын кыстый-кыстый чәй эчерми җибәрми. Мин дә экспозиция эргәсендә «җырлап» утырган самавыр янында гәпләшеп чәй эчә торган урын да булса икән дип хыялланам.

Автор фотолары

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,
филология фәннәре докторы, доцент, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре



ЧИЧӘН СҮЗЕ БЕР БУЛЫР

(Татар халык иҗатында чичән һәм җыраулар иҗатына караш)

СҮЗ БЕЛӘН ҖИҢҮЧЕЛӘР

Татар халкының гасырлар буе формалашкан рухи мирасында сүз осталары – чичәннәр һәм җыраулар аеруча зур урын алып тора. Алар, гади халык вәкилләре булсалар да, халык күңелендә тапкыр сүзе, тирән белеме һәм оста ораторлык сәләтенә ия булулары белән сакланып калганнар. Мондый иҗат вәкилләре – үзе яши торган җирлекнең күренекле уллары, хаклыкны яклаучылар. Һәр чичәннең үзенчәлекле үз стиле, үз тавышы-аһәңе булган, ләкин барысына да хас уртак сыйфат – ихласлык, ышандыру сәләте һәм гыйлемлелек – аларны «чичәннәр һәм җыраулар» дигән уртак атамага берләштерә. Безнең көннәргә кадәр мондый осталар турында риваятьләр, афористик сүзләр, мәкаль-әйтемнәр килеп җиткән, бу исә чичәннәрнең халык хәтерендә мәңгеләшкәнен күрсәтә. Чичән яисә җырау дип аталган күренекле иҗатчы-акыл ияләре җәмгыятьтә һәм, гомумән, татар мәдәниятендә югары урын тоткаллар.

Профессиональ җыраулар нәсел-дән-нәселгә тапшырыла килә торган осталыкларының үз чорында ук көннән-көн югала баруын искәртеп, галим А. Ходзько чичәннәрнең җәмгыятьтә биләгән урынына игътибар юнәлтә: «Алар нинди булганнар соң, дигәндә, иң яхшы үрнәк, бәлки бердәнбердер дә, ул – үзе шагыйрь дә, үзе тарихчы да, ватанпәрвәр һәм ханның зирәк, гадел киңәшчесе Сыбра җырау», – дип мисал китерә. Белгечнең әлеге сүзләреннән аңлашылганча, XIX йөз башында халык арасыннан чыккан җыраулар тормышта гаять югары функция үтәгәннәр, үзләренең иҗатлары белән фольклор сәнгатен буыннан-буынга тапшыруга күп көч куйганнар.

Чыннан да, халыкка хушаваз, дастан җырларын җиткерүче, тулгау, сарыннар әйтеп сөйләүче, эпос-дастаннарны көйләп җиткерә алучы чичәннәр – төрле яклап гаять оста кешеләр. Чичән булып җитешер өчен халык традицияләренә тугры шигъри текст төзү, күләмле текстны тоткарлыксыз тезеп әйтә белү, текстның сүзләрен я үзенчәлекле бер аһәң белән, я җырлап әйтү, музыка уен коралы белән эш итү – боларның

барысын да халык алдына чыгып, кул хәрәкәтләре, үз-үзеңне тотыш, мимика чараларын файдаланып, үтемле итеп җиткерә белү кебек сыйфатлар таләп ителә. Халык арасындагы дастанчы-чичәннәр, тыңлаучының кем булуыннан чыгып, үз чыгышларына тизлек белән үзгәреш тә кертә белгәннәр, шул очракта гына останың сүзе аудиторияне яуларлык көчле, тәэсирле булган.

Чичән иҗатында сүз белән бергә музыка, кайвакыт аерым хәрәкәтләр, жест, мимика куллану, театраль тамаша барлыкка китерү мөһим урын алып тора. Чичән башкарган иҗатта сәнгать башлангычы һәм фольклор тексты тыгыз үрелгән. Берничә дистә мең ел буена дәвам итә килгән чичәнлек үзе – милли-этник тарих, иҗтимагый-яшәеш үзенчәлекләре, менталитет, этник психология, милли тел байлыгы чагылыш тапкан зур бер процесс ул. Киң планда алганда, чичәннәр иҗатында һәм алар иҗаты буларак безгә килеп ирешкән һәрбер текстта болар барысы да катнаша.

«Күчәремне җил белә, кунарымны сай белә» яки чичән кем дә җырау кем.

Чичәннәр иҗаты – халкыбызның тел дәрьясы никадәр мул икәнен раслаучы билге дә. Чичәннәр образлы шигъри телдә көйләп-сөйләп биргән сүзләрнең үткенлеген, җорлыгын, тапкырлыгын такмак-такмазалар, мәкаль-әйтемнәр, янәшәлекләр, чагыштырулар, ирония, гипербола кебек тел-стиль һәм сурәтләү чараларын арттырган. Менә, мәсәлән, төп герое Җирән чичән булган борынгы мәзәктә атлар менеп сахрага йөрергә чыккан хан белән Җирән чичән турында сүз бара. Көз көне икән, халык телендә «пәри арбасы» дип йөртелгән тәгәри үләнен җил тәгәрәтеп алып бара, ди. Ханның, Җирән чичәннең сүзгә тапкырлыгын сыныйсы килеп: «Бар, шул тәгәрине куып җит тә сорашып бел кая бара, кая туктарга уйлаганын», – ди. Чичән тәгәрәп барган үлән артыннан куып җиткән дә, кире борылып килеп, ханга түбәндәге җавапны әйткән:

– Сорый килгән син тинтәкме, сората җибәргән хан тинтәкме, күчәремне җил белә, кунарымны сай (уйсу җир) белә, – дип әйтте, дигән [Мөхәммәтҗанова, 2025, № 1. 27–35 б.]. Бу мисалда татар халкының урта гасырлардан ук килүче образы – Җирән чичәннең тапкыр җавабы таң калдыра. Алай гына да түгел, кигә терелгән үрнәк чичәннәрнең хан янәшәсендә торучы югары вәкаләтле зат булуын ассызыклый. Җирән чичәннең ханга биргән үз-үзенә нык ышанган төпле һәм хикмәтле җавабыннан чыгып фикер йөрткәндә, мондый шәхесләр ханнар-түрәләр арасында үзләрен бик кыю тота торган булганнар.

Чичән булып җитешер өчен халык традицияләренә тугры шигъри текст төзү, күләмле текстны тоткарлыксыз тезеп әйтә белү, текстның сүзләрен я үзенчәлекле бер аһәң белән, я җырлап әйтү, музыка уен коралы белән эш итү – боларның барысын да халык алдына чыгып, кул хәрәкәтләре, үз-үзеңне тотыш, мимика чараларын файдаланып, үтемле итеп җиткерә белү кебек сыйфатлар таләп ителә.

«Чичән» – килеп чыгышы белән бик борынгы сүз. Гомумтөрки «чичән» сүзенең этимологиясен монгол теле белән бәйләп карау бар. Монгол телендәге «чэчэрхэ» сүзе (алтай: чэчэркэ, кыргыз: чечерке, якут: сэһэр һ.б.) «матур сөйләргә тырышу; тырышып күп сөйләү» дигәнгә туры килә [Татар теленең этимологик сүзлеге, 2015. 442 б.]. Доминантадан әллә ни ерак китмәгән мәгънәдә бу сүз, бераз фонетик үзгәрешләр кичереп, кыргыз, үзбәк, алтай, чыгатай, уйгур, кырымтатар, казах, башкорт, нугай, каракалпак, якут, чуваш, тува телләрендә очрый. Бу сүзнең Кытайдан башлап Евразия далаларында таралып яшәүче төркиләрдә булуы, Идел буенда яшәүче татарларда кулланылуы чичән иҗатының бу халыкларның һәммәсендә киң таралган булуын күрсәтә.

Монголларда, бурятларда, якут, тунгус, тува, хакасларда, алтай төркиләрендә, каракалпак, нугай, казахларда, Кавказ халыкларында, шул исәптән карачай-балкарларда һ.б. халыкларда

соңгы көннәргәчә эпос эчтәлегендә мөһим урын били торган каһарман сүзен, ягъни эпик җырны гына түгел, әсәрнең үзен тулы килеш тоташ музыка коралында уйнап (кубыз, саз, чатхан, татхан, дутар, думбра, топшур, комус, кифара һ.б.), ярым көйләп яки музыкаль речитатив белән башкару үрнәге сакланып килә. Мондый төр иҗат әлеге һ.б. халыкларда элек тә билгеле бер йола контекстында башкарылган һәм аудитория эпик әсәрне шушы эш белән махсус шөгыльләнүче талант иясе – чичән авызыннан ишеткән. Әйтик, кыргызлар һәм казахларда атаклы «Манас», «Кобланды», «Алпамыш»ны яу алдыннан билгеле максатларда сугышчылар каршында башкарулары, тува, хакасларда шулай ук сүз остасының ыруг-кабилә сунарчылары алдында тайгада эпос әйтүе кайчандыр жанрның йола үтәү белән дә тыгыз керешкәнлеге хакында сөйли. Бу исә чичәннәр иҗатының никадәр тирәннән үк килүен һәм иҗтимагый әһәмиятен ассызыклый.

Төрки халыклар эпик поэзиясен гомер-гомергә чичәннәр тоткан, хәзерге вакытта да халыкта чичәнлек функцияләрен башкаручы осталар җитәрлек. Чичәнлек традициясе татарларда бүгенге көндә дә исән дип ышанып әйтә алабыз. Соңгы елларда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан татарлар яши торган төрле төбәкләргә оештырылган фәнни экспедицияләрдә язып алынган дастан җырлары, хушавазлар, тарихи җырларны хәтерендә яңарта алучы һәм, гомумән, мәкаль-әйтемнәр кулланып сөйли белүче сүзгә оста информантлар очрап тору – шуңа мисал.

Чичән кем дә, җырау кем дигәндә, бу сүзләрнең синонимнар булуын әйтеп китик. «Jir» сүзе («җыр», «йыр») Мәхмүт Кашгариның борынгы төрки сүзлегендә очрый [Махмуд ал-Кашгари, 2005]. Аның мәгънәсе эпик героик тезмә сүз дигәнне аңлата. Охшаш яңгырашта бу сүз күпчелек төрки халыкларда кулланыла. Мәсәлән: якут телендә – «ырыа», хакас һәм кыргыз телендә «ыр», башкорт телендә «йыр» казах һәм нугай телендә «жыр». Мондый тезмәдән гыйбарәт җырны речитатив дип атарга була, аның әлеге мәгънәсен инглиз телендәге «рэп» дигән төшенчә дә аңлата.

Җырау – төрки халыкларда киң таралган образ. Бу гади хикәяләүче яисә көй көйләүче генә түгел, ә акыл иясе һәм идеолог, халыкны югары идеалларга өндәүче җыручы-көрәшче. Җыраулар халык массалары арасында һәрвакыт аерылып торган. Һәр чорның үз җыравы булган. Алар – халык иҗаты стилендәге образлы телдә, ешрак шигырь-музыка рәвешендә мистик һәм реаль вакыйгаларны һәм халыкның тарихи тәҗрибәсен җыр белән әйтеп сөйлиләр, үткәнне үз чорлары белән бәйлиләр. Импровизатор, җырчы һәм сәнгатьче буларак, җырау, халык уй-хыялларын, өметләрен җиткереп, бик сирәк, аеруча кирәк очракларда гына чыгыш ясаган. Бөтенхалык абруе булган җырауга, аның киңәшенә, нинди дә булса гомуми борчылулар, дулкынланулар вакытында мөрәҗәгать иткәннәр, халык кризисы, фетнәләр һәм Ватанга чит ил баскынчылары куркыныч янаганда аларга ихтыяҗ арткан. Җырау үтемле шигъри сүзе белән халыкны тәртипкә чакырган, аны илһамландырган, вакыйганың нәтиҗәсен, пәйгамбәрләрчә, алдан күреп әйткән. Болардан чыгып, бүгенге көндә фольклористикада аерым бер жанрны халыкка җиткерүчеләр дип карала торган җыраулар үз заманында аналитиклар да, сәясәтчеләр дә, хан-түрәләрнең киңәшчеләре дә булганнар.

ТАТАР ТАРИХЫНДА ҖЫРАУ-ЧИЧӘННӘР

Татар чичәннәре турында мәгълүматны бик сирәк чыганактан табарга мөмкин, чөнки сүз остасы чичәннәр тарафыннан халык алдында думбра чиртеп дастан әйтү традициясе утрак тормышка иртә күчкән, шәһәр мәдәнияте алга киткән, күңелен китап, басма сүз яулаган укымышлы татарларда башка кайбер төркиләргә, әйтик, казах, нугай, саха, башкортларга караганда алдарак сүрелгән. Шуңа бәйле татар чичәннәре иҗаты гадәти юл белән генә түгел, китаби-язма рәвешкә дә күчеп үсеш алган. Әмма әгәр үткән чорларда татарда чичән һәм аның эпос-дастан, хушаваз, тулгау, үләң, сарыннарны көйләп әйтү гадәте булмаган булса, бүген халыкның «Кузы Көрпәч белән Баянсылу», «Алпамыш», «Түләк», «Идегәй», «Чура батыр» кебек гүзәл дастаннары, әле дә очрап тора торган дастаннан эпик җыр башкарулар берсе дә булмас иде. Боларның барысының

тамырлары – халыкның телдән әйтеп башкара килгән сүз сәнгатендә, чичәнлек традицияләрендә.

Чыннан да, саный китсәк, Идел-Урал төбәгенең шагыйрь-импровизаторлары саналган Әсән (Хәсән) Кайгы (XV гасыр), Катбога, Казтуган җырау (XV гасыр), Дусмәмбәт җырау Азаулы (XV г. икенче ярт. – XVI г. 20нче еллары), Чалгиз (Шалкиз) җырау Теләнче углы (XV гасыр ахыры – 1560 еллар), Парыздак Чабанулы, Коба җырау Кыпчак, Кара-баис Каңгылы, Озын Айдар, Коңгырат, Сылумамбәт бахшы Ширин, Манкы җырау Мангыт, Морын җырау Сеңгирбек улы (1859–1954) һ.б. ны шул чорның мәгълүм чичәннәре дип атыйлар. Болардан күбесе хакында шактый тулы мәгълүматлар килеп җиткән булса, кайберләренең исемнәре тарих тузанына күмелеп калган. Кайбер чичәннәрнең безнең көннәргә бик аз санда гына һәм нигездә өзекләр булып килеп җиткән әсәрләре билгеле, бу борынгы уникаль иҗат әһелләре хакында мәгълүматны барыннан да бигрәк аларның әнә шул сакланып калган язмаларыннан табарга мөмкин. Арада кайберләренең, аерым алганда, яшәгән еллары соңгырак чорга карый торганнарының, күпләгән эпос-дастаннарны һәм шуңа охшаш иҗатны җырлап җиткерүләре мәгълүм. Татарларның Урта Азия далаларына сибелеп яшәгән дисперс халык булуын исәпкә алмыйча, соңгы елларда әлеге шәхесләрне татар мәдәниятеннән читләштереп, кардәш төркиләргә генә нисбәт итү тенденциясе артты. Ә чынлыкта татарларның бик борынгы халык булулары мәгълүм һәм аларның тамырлары гаять тирән, шуңа күрә югарыда телгә алынган атаклы чичән-җырауларны татарларга нисбәт итәргә тулы хакыбыз бар.

Чичәннәрнең күләмле текстларны хәтерләренә беркетеп, тоткарлыксыз әйтә алулары – феноменаль күренеш. Әйтик, Мангыстау өлкәсе (хәзерге Казахстан территориясенә керә) нугай чичәне Морын җырау (Теләгән Сеңгирбек улы (иҗаты XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөзнең беренче яртысына карый) – үз гомерендә ике йөздән артык эпос-дастанны җырлап җиткергән оста. Морын җырау «Кырымның кырык батыры» циклына керә торган фольклор ядкәрләрен башкаруы белән дан тота. Аның репертуары аша татар халкында да киң таралган «Алпамыш», «Котлыкыя», «Идегәй», «Нурадын», «Чура батыр», «Күруглы батыр», «Муса хан» кебек кадерле мирас килеп җиткән. Морын җырау – үзе яшәгән территориянең Кашаган җырау, Нурым җырау исемнәре белән тарихка кергән нәселдән-нәселгә килгән чичән-башкаручыларның шәкерте.

Соңгырак чор чичәннәренә тукталсак, XX йөзнең 20нче еллары башында Н. Исәнбәт Башкортстанның Сәет авылында Фәйзулла исемле чичәннән борынгы җырлар яздырып ала, шулай ук Башкортстанның элеккеге Бөре өязеннән сукыр Фәррах (Фәррах Дәүләтшин) белән якыннан аралаша, аның хакында «Сүз табучы Фәррах», «Фәррах җырлары турында» дип язып та чыга [Исәнбәт, төз. М.М. Хәбетдинова, 2021. 487 – 489 б.]. Чичән кешеләр бүген дә бар, татарларда чичәнлек традицияләре сулган дип нәтиҗә ясап булмый. Безнең көннәрдә дә тикшеренүче-галимнәр чичән-җыраулар иҗатына юлыгып тора, моңа мисаллар җитәрлек.

СУБРА ҖЫРАУГА НИЧӘ ЯШЬ?

Җыраулар, әллә ничә гасыр элек яшәп киткән булсалар да, фольклор хәтере буларак, шактый озын гомер кичерәләр. «Идегәй» дастанындагы Субра (Сыбра) җырауның 195 яшьлек хикмәт иясе буларак тасвирлануында, мәсәлән, зур мәгънә бар. Алтын Урданың таркалу чоры вакыйгаларын бәян итә торган дастан, Субра җырау сүзләре һәм акылы аша, үз чорыннан күп алда яшәгән буыннарның тәҗрибәсен бәян итә. Бәлки, Субра җырау дастан иҗат ителгәнгә кадәр берничә гасыр алда яшәп киткән чичән булгандыр, әмма дастанда әлеге хикмәт иясенә мөрәҗәгать итү аша аның әйткәне һаман да билгеле бер көчкә ия булуы тасвирлана. Чыннан да төрки әдәбиятта һәм фольклорда Субра җырауның иң якты образы. Субра, Сыбра, Сабра, Хабрау, Сәфәрдау, Сыпыра исемнәре белән ул «Идегәй» эпосының барлык вариантларында да катнаша. Төрле вариантларда ул – 120, 180, 360, 500, 1000 яшьлек карт.

Дастанның Н.Исәнбәт вариантында, мәсәлән, җырауга 195 яшь. Шуннан чыгып, «Идегәй» дастанында чичән авызыннан әйтелгән сүзнең гасырларны иңләвенә ишарә бар, дип уйлый алабыз. Туктамыш хан тарафыннан Субра җырау, меңьяшәр карт буларак, мәҗлескә чакырыла:

Анда Субра ерауны
Биленә пута будырып,
Яңакларын бәйләтеп,
Азауларын чиратылган
Чи ефәк белән чорматып,
Алтынлы көймәгә менгезеп,
Култыгына җизле таяк сөятеп,
Кулына алмас кундырып,
Күзенә сөнбел сөрттереп,
Үтрек–ялган димәскә
Иман шәһадәтен искәртеп,
Ханга алып киттеләр.

[Идегәй. Татар халык дастаны].

Субра җырауның сарайдагы чыгышы Туктамыш хан сараенда үскән, Идегәй исеме белән мәгълүм Кобогылның тәрҗемәи хәлен, аның кем булуын, киләчәген, шуңа бәйләп, илләр-дәүләтләр язмышын эпик тезмә юлларда әйтеп бирү белән характерлана:

Бездән борын заманда
Тунику атлы хан үтте,
Яу булганга яу булды,
Ил булганга ил булды.
Олы ханның уагы,
Уак ханның олысы
Туникуга баш иде.
Тунику күктән ашканда,
Кытай йортын басканда,
Аның олы вәзире –
Тат торуны Колатай,
Даладан табып бер бала,
Тарун булып үстерде.

[Идегәй. Татар халык дастаны].

Ахыр килеп, дастанда Субра җырау сүзенең хаклыгы раслана. Игътибар итсәк, татарның иң атаклы дастаны «Идегәй»нең поляк шагыйре, көнчыгышны өйрәнгән галим, күп телләр белгече Александр Ходзько тарафыннан Әстерханда татар кешесеннән – Галибәк Шараповтан 1830 елда татар телендә ишетеп, фарсычага тәрҗемә ителгән, соңыннан шулай ук А. Ходзько тарафыннан инглиз телендә Лондонда бастырып чыгарылган [Adiga, 1842. P. 348-362], шактый катлаулы юл үтеп безгә килеп ирешкән вариантында казах чыгып киткән Идегәй турында мәгълүмат җыярга дип, Туктамыш киңәшчеләрен чакырта. Аларга бер–бер артлы сүз бирә. Иң элек ул шушы җыенның башлыгы Хәсән углы Ходайбирдегә мөрәҗәгать итә, әмма Ходайбирде җавап бирә алмый. Аннан Кенәгәс ыруыннан Кус углы Җамбай фикерен тыңламакчы булып, аңа сөйләргә әмер бирә, Җамбай да берни әйтә алмавын белдерә. «Алай булгач, Акмуса, син әйт!» – ди хан. Акмуса болай ди:

«Әй ханым минем! Аллаһның миннән дә картрак кешесе бар, ул инде туганыннан алып өч йөз алтмыш яшь яшәгән, аның тешләре селкенеп тора, әмма зиһене ачык, ул кеш тиресеннән бүрек кия. Аның исеме Сыбра. Аны китерт».

Шуннан Туктамыш үзенең атларын алтын арбага җигәргә куша, атларның тоягын алтын дага белән дагалата, дагалар тоякларга көмеш кадаклар белән беркетелгән булсын, дип әмер итә, ат ябуын алтыннан ясатырга куша, «Барсыннар да Сыбраны монда алып килсеннәр», – ди.

Сыбраны тотып алып, хан каршына китерәләр, хан түренә узгач, җырау сүзен түбәндәгечә башлый:

– Әй ханым минем! Сөйләргә әмер бирсәң, мин сөйлим. Әмма коры үләннең суы юк, коры сөякнең мие юк. Карт кешенең зиһене зәгыйфь. Хан канәгать калмас [Мөхәммәтҗанова, Казан утлары, 2023, № 9. 169–170 б.].

Шуннан соң дастанның Ходзько вариантында бик күп вакыйгалар җырау сүзләре аша сурәтләнә, аның әйткәннәре ышанып кабул ителә һәм, чыннан да, өстен чыга, раслана. Сыбра җырау үзенең гади генә кеше түгеллеген дәлилләп, мондый сүзләр сөйли:

«Әй ханым! Мин күпләрдән өлкәнрәк. Мин бик күп бөек ирләрне күрдем, мин Әхмәтханны, синең карт бабаңның бабасы Чыңгызханны алтын киемнәрдән күрдем. Мин Караханны һәм Буракханны, Халкман Гурганны һәм Җучи ханны, Устимер ханны, әлеге тиңе булмаган ханны, мин шулай ук күрдем. Хивада булган чагымда егерме ханны күрдем, Үргәнечтә – өч ханны. Бохарада – Габделхәер ханны, Сәмәркандта Җәйбәк ханны күрдем. Ташкентта бөек ханны күрдем, Җанибәк хан кодрәтенең шаһиты булдым. Ул чүлдә кыйммәтле зиннәтләр белән бизәлгән сарай төзетте, диварларына мең ат бәйләрлек мең боҗра тактырды...». «Мин Гарәфәтнең мәрмәр сарайларында булдым. Мин пәһлеван Хәмзәнең бөек көрәштә сугышуын күрдем. Алтын тоткалы корыч кылычымны

кулга алып, мин аңа ярдәмгә ашыктым. Мин Сөләйман пәйгамбәрне очраттым һәм аннан ярлыкау сорадым. Мин аннан мине падишаһ итеп билгеләвен үтендем һәм ул миңа тәхет бирде, мин аның үз кулыннан тәхет алдым. Әмма бөтен нәрсәне Аллаһ ярдәмендә башларга күнеккән гадәтем буенча, мин гыйбадәтсез килеш тәхеткә утырырга теләмәдем. Кодрәтле Аллаһ минем теләгемне ишетте, Җәбраил фәрештә: «Амин! Амин!» – диде».

Мисаллардан аңлашылганча, җырау юк-бар сүз сөйләми, үз дәрәҗәсен һәм сүз кадерен белеп сөйли. Чичән сүзенә олысы-кечесе, шул исәптән, хан-солтаннар колак сала, аны зурлап, хөрмәт күрсәтә.

ТАТАР ЧИЧӘННӘРЕ МИРАСЫН БАРЛАУ – ТАРИХЫБЫЗНЫ ТЕРГЕЗҮ

«Чичән», «җырау»лар иҗатын өйрәнү кебек фәнни проблема фольклористикада татар халык җырлары мәсьәләсенә кагылганда да, эпос-дастаннарны өйрәнгәндә дә моңа кадәр читтә кала килде. Әмма татар фольклорын сүз сәнгате буларак караганда да, синкретик иҗат буларак, башкарылу һәм аудитория тарафыннан кабул ителү җәһәтеннән барлаганда да дастан һәм хушавазларның, тулгау, сарын, үләҥнәрнең җырлап тапшырылуын читләп үтеп булмый.

Бу – бүгенге фольклористикада лирик төргә карый торган «җырлар» һәм эпик төргә карый торган «дастаннар» дип аерымланган жанрларны, тагын да тирәнрәк чорларга төшеп, бергәлектә карауны таләп итә торган зур тема. Чичән иҗатында лириклык һәм эпиклык тоташа. Лирика һәм эпос – әдәбиятның гына түгел, фольклорның да бик борынгы төрләре. Аларның башлангычы – нәкъ менә халык иҗатында. Җамукай чичән, Субра (Сыбра) җырау, Җирән чичән кебек шәхесләр – татар халык сүз сәнгатенең чын мәрҗәннәре. Алар – үз заманының күренекле фикер ияләре, җәмәгать алдында утлы сүзләре белән күңелләргә үтеп керүчеләр. Татарның чал тарихында халык гаделлек эзләгәндә нәкъ менә чичән сүзе көч биргән, яхшыга рухландырган, берләштергән. Җыраулар эпос-дастаннарны, тулгауларны, сарыннарны, хушавазларны башкарганда үзләренең тирән фикерләрен халыкка аңлата алганнар, батырлык, затлылык, кардәшлек-туганлык, ата-баба, ил-йорт кадере кебек мәңгелек кыйммәтләрне халык күңеленә салганнар. Татар тарихын борынгы катламнарга ук төшеп өйрәнгәндә җыраулык-чичәнлек традицияләре аша күп сорауларга ачыклык кертергә мөмкинлек туа, шуңа да җыраулар һәм чичәннәр мәсьәләсен өйрәнү һәр заманда актуаль һәм җитди тема булып калачак. Җыраучичәннәр иҗаты бабалар рухын саклый, шул ук вакытта үткәнне бүгенге һәм киләчәк белән бәйли.

Алар – халык иҗаты стилендәге образлы телдә, ешрак шигырь-музыка рәвешендә мистик һәм реаль вакыйгаларны һәм халыкның тарихи тәҗрибәсен җыр белән әйтеп сөйлиләр, үткәнне үз чорлары белән бәйлиләр. Импровизатор, җырчы һәм сәнгатьче буларак, җырау, халык уй-хыялларын, өметләрен җиткереп, бик сирәк, аеруча кирәк очракларда гына чыгыш ясаган.

Әдәбият

Махмуд ал-Кашгари. Диван Лугат ат-Турк / Перевод, предисловие и комментарии З.-А. М. Ауэзовой. Индексы составлены Р. Эрмерсом – Алматы: Дайк-Пресс, 2005. – 1288 с.
Мөхәммәтҗанова Л.Х. Мәзәкләрдә – күңел көрлеге // Түгәрәк уен. 2025, № 1. 27 – 35 б.
Мөхәммәтҗанова Л.Х. Янә «Идегәй» хакында. «Идегәй» дастанының Г. Шараповтан Александр Ходзько тарафыннан язып алынган варианты // Казан утлары. 2023. № 9 (1211). 166 – 172 б.
Татар теленең этимологик сүзлеге. 2 томда. Т. 2. (М-Я). – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2015. 567 б. 442 б.
Adiga / Chodzko A. Astrakan tatar songs // Specimens of the popular poetry of Persia. London, 1842. P. 348-362.
Идегәй. Татар халык дастаны // https://mybook.ru/author/eposy-legendy-i-skazaniya/idegj-tatar-halyk-dastany
Исәнбәт Н. Фәррах җырлары турында // Нәкый Исәнбәт: фәнни-популяр җыентык / Төз. М.М. Хәбетдинова. – Казан: Җыен, 2021. 487 б.

МУЗЕЙЛАРДА ТАРИХИ ХӘТЕР: МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

«Мин ант иттем җанны кызганмаска, Саклар өчен халкым, илемне...»



Казанның Горький урамындагы 17 нче йортны заманында мәгариф, мәдәният, сәнгать әһелләре өчен дип төзиләр. 1940 елның октябрендә бу йортның 28 нче фатирына гаиләсе белән Татар опера театрының әдәби бүлеген һәм Татарстан язучылар берлеген җитәкләгән (1939–1940 елларда), Казан шәһәр советына депутат итеп сайланган Муса Җәлил күченеп килә.

Аңа коммуналь фатирда озак юанырга туры килми – 1941 елның июлендә фронтка китә. 1983 елның 15 феврале, ягъни шагыйрьнең туган көнендә алар яшәгән әлеге фатирда музей ачыла. 12 елдан соң янәшәдәге өч бүлмәле фатир хисабына Муса Җәлил музей-фатирының мәйданы киңәйтелә.

Музейдагы һәр экспонат турында аерым туктап сөйләргә мөмкин, чөнки һәрберсенең үз тарихы. Мәсәлән эш өстәлен Муса Җәлил 1935 елны Мәскәүдә комиссион кибеттән сатып алган. Шагыйрьнең күп кенә әсәрләре, шул исәптән «Хат ташучы»



поэмасы һәм «Алтынчәч» операсының либреттосы нәкъ менә илһам утравына тиң әлеге өстәлдә иҗат ителгәннәр. 200 дән артык китап сыйдырган шкафы. Диварда эленеп торган мандолинасын ул, мөгаен, күңеле моңга сусаганда, яки киресенчә елга булып ташыганда кулына ала торган булгандыр...

Билбау алмашу – яңадан очрашуга ышаныч билгесе

Муса Җәлил белән композитор Нәҗип Җиһановлар бер үк подъездда яшәгәннәр. Менә Н. Җиһановның 1940 елның 19 сентябрендә хатыны Серафимага язган хатыннан өзек: «Мне дали хорошую квартиру из трёх комнат со всеми удобствами. Квартира хорошо отделана. Единственное, что может тебя не удовлетворить, так это первый этаж». Җәлиловларныкы дүртенче катта ике гаиләгә уртак кухнялы коммуналь фатир булып, өч бүлмәнең икесе аларныкы булган. Шуларның берсе – шагыйрьнең эш бүлмәсе, икенчесе «торак бүлмә» саналган.

Муса Җәлил белән Нәҗип Җиһановны егерменче гасырның 30 нчы елларында шагыйрьнең дусты Әхмәт Фәйзи таныштыра. Бу Җәлилнең опера студиясендә эшләгән чоры, Җиһанов исә Мәскәү консерваториясе студенты. 1938 елда ул, Җәлилнең тәкъдиме белән, «Алтынчәч» операсын язуга алына һәм аларның иҗади дуслыгы шулай башлана. Уртак иҗат җимеше буларак «Алтынчәч» һәм «Илдар» опералары туа.

«Бу операларның һәр икесе минем һәм композитор Җиһановның, бер-беребезгә бик якыннан торып, бер-беребезнең иҗатын тирән төшенеп, чын мәгънәсе белән иҗат дуслыгы һәм булышлыгы нигезендә эшләвебез җимеше булып тудылар. Без операда поэзия белән музыканың идеаль бердәмлеген, чын гармониясен булдырырга омтылдык», – дип язган шагыйрь.

«Эш барышында яңа операләр турында да сүз күп булды», – дип искә ала Н. Җиһанов, ләкин Бөек Ватан сугышы башлана.

Муса Җәлилне ике мәртәбә фронтка озаталар. 1941 елның 13 июлендә китәргә повестка килгәч, ул Курск өлкәсенә политхезмәткәрләр курсына укырга җибәрелә. Алар фронт сызыгына якынлашкач тылга – Минзәләгә күчерелә. Курслар тәмамланганнан соң, Җәлил бер атналап гаиләсе янында яши һәм 1942 елның 8 гыйнварында сугышка китә.


Бу көннәр турында Нәҗип Җиһановның истәлекләрендә мондый юллар бар: «Мусаның фронтка китәсе көненә каршы төндә без караңгыландырылган Казан урамнарында озак йөрдек. Күп нәрсәләр турында, башлыча сугыш турында, авыр сынаулар турында сөйләштек.

– Фашизм бөтен кешелек дөньясына кизәнде. Билгеле, без җиңәчәкбез, ләкин сугыш авыр булачак... Исән-сау кайтасы килә...

Һәм, саубуллаша башлагач, Муса тәкъдим итте: «Әйдә, ата-бабаларыбыз гадәтен искә төшерәбез. Ерак һәм куркыныч юлга чыгу алдыннан алар бер-берләре белән билбауларын алмашканнар. Бу яңадан очрашуга ышаныч билгесе булган».




Муса Җәлил



Нәҗип Җиһанов






Шулай итеп, Муса Җәлилнең билендә йөргән каеш композиторда сакланып кала. Бүген ул кадерле ядкәр буларак музейда саклана.

Коръән китабы

Өченче Рейхның II Империя суды карары белән фашистларга каршы пропаганда һәм Германиянең хәрби куәтен какшатуда гаепләнгән 11 татар кешесе Гайнан Кормаш, Фуат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фуат Булатов, Муса Җәлил, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Галләнур (Сәлим) Бохаров 1944 елның 25 августында Берлинның Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелә.

Башларын палач балтасына куярга бер сәгать кала алар янына Берлиндагы татар комитетында мулла вазифаларын үтәгән Гани Госман (ул I Бөтендөнья сугышында әсирлеккә эләгеп, Алман илендә яшәп калган кеше була) керә. Җәлилчеләр ул алып килгән Коръән китабына кулларын куеп: «Бәхил булыгыз, бәхил, бәхил», – дип мәңгелеккә дөнья белән хушлашкан. Аларның кул җылысын саклаган әлеге Коръән китабы Татарстанга урау юллар аша кайта. Гани Госман 1950 елны вафат булганнан соң, тарихи вакыйгаларның шаһиты булган Коръән китабы баштарак аның дусларында, аннан Америкада яшәүче татар эмигранты Абдулла Вафалы кулына килеп керә. Безнең олпат язучыбыз, әдәбият белгече һәм тарихчы-галим, академик Миркасыйм Госманов та аны





Америкада әлеге гаиләдә кунакта вакытта күрә. Абдулла Вафалы 9х12,5 см зурлыктагы 876 биттән торган әлеге Коръәнне Татарстанга 1993 елны, I Бөтендөнья татар конгрессына килгәндә алып килә һәм Миркасыйм Госмановка тапшыра. Китапны М.Җәлил музей-фатиры фондына тапшыручы да ул. Баштагы өч ел дәвамында экспозициягә китапның төп нөсхәсе куела, ә хәзер тарихи экспонатны саклау максатында ул фондта саклана, музейга килүчеләр күчермәсе белән таныша.



Шахмат – дуслык символы

Өстәлдә шахмат тактасы. Әлеге шахмат – Җәлилнең иң якын дусты әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче Гази Кашшафныкы (Миргази Солтан улы Кашшафетдинов. 1907–1975). Сугыштан соң Гази Кашшаф М. Җәлилнең исемен аклау, реабилитацияләү һәм иҗатын таныту өчен зур көч куя. Беренчеләрдән булып «Моабит дәфтәрләре» нә фәнни шәрехләүләр төзи; Җәлил турында замандашларының истәлекләрен туплап чыгара; шагыйрьнең фотоларыннан альбом төзи; татар телендә өч, рус телендә бертомлык сайланма әсәрләр бастыра.

Җәлил чыннан да шахматны үз иткән, уен барышында отса – сөенгән, оттырса, үзен-үзе «грошмейстр» дип атаган. Дус-иш белән бергәләп «Шахматный бюллетень» дигән стена газетасы да чыгарганнар.

* * *

Гомумән, Татарстан Республикасы Милли музее фондларында шагыйрьнең тупланмасы шактый саллы. Исән чагында нәшер ителгән 12 басмасы, шул исәптән рус теленә тәрҗемә ителгән беренче җыентыгы («Стихи», М., 1935) саклана. Хронологик яктан басмалар 1925–1944 елларны үз эченә ала, аларның гомуми тиражы 50 405 данә тәшкил итә.

Фотолар Муса Җәлил музей-фатиры архивыннан

РУХИ КОДЛАРНЫҢ, сихри тоем белән бәйле йолаларның иҗаттагы урыны

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,
язучы, әдәбият белгече



МИҢА БУ ХАКТА СҮЗ БАШЛАРГА 2008 ЕЛНЫҢ 26 АПРЕЛЕНДӘ БУЛГАН БЕР ВАКЫЙГА ЭТӘРГЕЧ БИРДЕ. ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУГАН КӨНЕНДӘ УЗА ТОРГАН ТРАДИЦИОН «ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ»НДӘ БУЛДЫ БУ ХӘЛ.

Ирек мәйданы. Дөнья татарларының иң зыялы, иң талантлы уллары, кызлары мәшһүр Тукайның рухы алдында баш иргә җыелган. Германиядән кайткан дустым Нәсүр Юрушбаев белән шушы бөек рухның сихри шаукымында шигъри митингны манзара кылып торабыз. Ә ул кызганнан-кыза. Шагыйрь һәйкәле каршына бер-бер артлы шагыйрьләр күтәрелә. Бар җир, күк, дөнья шигырь аһәңендә, шигърият гипнозында яши. Бер тетрәнеп, бер моңланып яисә дәртләнеп, ягъни горурланып, ШИГЫРЬ тыңлыйбыз. Һәр мизгел саен йөрәк ешрак тибә, күңел үзенең арыган, авырайган канатларын киңрәк җәя...

Шулвакыт баш очында сәер вакыйга башлана. Янәшәбездәге күтәрмә мәйданчыкта телевидениегә төшерү белән мәшгуль булган оператор, дөньялык белән багланышын югалтып, телекамерасыннан аерылып китә дә читкә ава башлый... Аяк буыннары йомшап, мәйданчык өслегенә чүгеп төшмәсә, өч метр биеклектәге каланчасыннан «очып» төшәчәк иде, биллаһи!

Без, ягъни Нәсүр белән мин, беренчеләрдән булып, өскә, җилдә дулкынланган кылган кебек, калкынып-чүгеп торучы оператор егет янына томырылып менәбез. Аның агарынган йөзен, мәрткә китеп барган күз карашларын күреп, телсез калабыз, җан түренә ургылып суык керә башлый...

Ул вакытта каушап калырга ярамый иде, аска карап, кемгәдер якында гына торган «Ашыгыч ярдәм» машинасын чакырырга куштык та мәйданчыгында йомарланып утырган егетнең йөз-битенә су бөркергә, аның агарып-зәңгәрләнә башлаган яңакларыннан, маңгаеннан, кул-беләкләреннән ышкырга, сыйпарга, чигәләрен уарга тотындык.

Аска төшереп, табиблар кулына тапшыргач та оператор егетнең яныннан китмәдек. Ул, айнып, бик тиз аягына басты, күзләрен ачты, бераз хәл алгач, үзенең профессиональ эшенә кереште...

Бу бик сәер күренеш иде. Шуңа да табиблардан сорамый булдыра алмадым:

– Нәрсә булган соң аның белән?

– Белмибез шул, – дип җавап кайтарды табиб, гажәпләнүен яшереп бетерә алмыйча, – бөтен җире дә нормада, басымы да, йөрәге дә, психикасы да... Медицина чире түгел бу. Ул нинди дер бик көчле сихри шаукым, энергия тәэсире кичергән...

Табиб акыллы кеше булып чыкты. Ул шул бер сүз белән барысын да аңлатып бирде: оператор егетне Тукай һәйкәле янына җыелган татарларның рухи энергиясе, ягъни рухи, иҗади шаукымы «суккан» иде. Хәзер уйлыйм: ә бит мин үзем дә бу шаукымны аермачык тоя башлавымны сизгән идем, ул вакытта баш очыбызга җыелган рухи ажаганнарның магик егәрлегеннән йөрәгем җилпенеп, җилкенеп тибәргә керешкән иде...

Мин шул көнне беренче мәртәбә иҗади, дөресрәге, рухи энергиянең материальләшүен, реаль көчкә әверелүен күрдем. Иң мөһиме, бу көчнең сихри дулкынланышына кайбер җаннарның ялкынсына алуына инандым.

«Шигърият көне»ндә оператор егет белән булган хәлдән соң миндә «иҗат» һәм «магия» мөнәсәбәтләре хакында мәкаләләр циклы язу теләге уянган иде. Моңа кадәр өйрәнелмәгән, ачылмаган, әдәбият, сәнгать, иҗат магиясе белән бәйләнешле, кайбер серләрне ачасы, өйрәнәсе килде, ачыклап бетерергә мөмкин булмаса да, чынбарлык белән сихри хыялыйлыкны аерып торган пәрдәне аз гына булса да күтәреп карау теләге туды. Һәм мин, ниндидер бер үҗәтлек белән, әдәбиятыбызның тылсымлы сәхифәләрен актара башладым. Чынлап та, әдәби иҗатта, әдипләр тормышында шаукымлы серләр ай-һай күп булып чыкты. Язмыш юраучы вакыйга-фалларның, образ-символларның, рухи кодларның, күрәзәлек, сихри тоем белән бәйле йола-ритуалларның зур иҗатта никадәр мөһим урын тотуын моңа кадәр күз алдына да китерә алмаганмын икән!

КОЛ ГАЛИ ҺӘМ МУСА ҖӘЛИЛ

Әдәби иҗаттагы серле-магик бәйланышларга инде гаҗәпләнмибез дә. Дөнья-яшәеш чикләре аша, вакыт-тарих катламнары аша үтеп-сүтеп йөри торган магнит дулкыннарының кайсы ярга кагачагын тиз генә әйтеп бетереп тә булмый.

Шулай да күңелдә бернинди шик уятмый торган бер иҗади бәйланыш, серле йогынты хакында күптән билгеле. Ул – мәшһүр Кол Галинең 1233 елның 12 маенда тәмамланып, халкыбыз рухи мирасының алтын баганасын тәшкил иткән «Кыйссаи Йосыф» дастаны белән XX гасырның патриот шагыйре Муса Җәлилнең атаклы «Моабит дәфтәрләре» арасындагы бәйланыш.

Башта ук шуны искәртеп үтәргә кирәк: М.Җәлил Кол Галинең әсәрен бик яхшы белгән. Бу хакта туганнары сөйләгән истәлекләрдән беләбез. Әлбәттә, Мусаның бала чактан әлеге дастан-поэманы өлкәннәрдән тыңлап үсүе, күңеленә алуы бер якты хатирә буларак кына кабул ителергә мөмкин. Ләкин шул да мәгълүм булсын: үзенең «Алтынчәч» либреттосын язганда шагыйрь, бу үлемсез әсәрне тагын бер мәртәбә укып, өйрәнеп чыга...

Ике әсәрне янәшә куйсак, иң элек шул күзгә ташлана: «Кыйссаи Йосыф»та да, «Моабит дәфтәрләре»ндә дә тоткынлык хакында, әсирлеккә төшкән геройларның катлаулы, әмма данлыклы язмышы, каһарманлык миссиясе хакында сүз бара. Аларның темасы, мотивы, сюжет эчтәлеге генә түгел, бөтен образлар системасы, поэтик сурәтләү чаралары, стиле, хәтта аһәң-интонациясе шушы тоткынлыктагы көрәш идеясе белән бәйле. Хәтта шундый фикергә киләсең: Кол Гали дә, Муса Җәлил кебек, үзенең атаклы әсәрен әсирлектә чакта, кискен көрәш һәм сынау-сыналу мохитендә язмады микән?

«Кыйссаи Йосыф» дастанының тоткынлыктагы милләттәшләребез өчен рух саклау, рух ныгыту китабы булуы хакында иң элек әдәбиятчы-галим Нурмөхәммәт Хисамов әйтә: «Беренче бөтендөнья сугышында немец әсирлегендә булган татар сугышчылары үзләрен, бәхетсез язмышка тарып, чит илгә элэккән Йосыф итеп күз алдына китерәләр, ә туган аталарын Ягъкуб белән чагыштыралар. Шул рәвешчә, халык китабы «Кыйссаи Йосыф» татар егетләрен туган ил белән тоташтырган рухани күпергә, патриотизм юлдашына әйләнә» (Кол Гали. «Кыйссаи Йосыф» – Казан: Татар. кит. нәшр.,1989 ел, 8 бит).

Мәгълүм булганча, «Җәлил» – Аллаһы Тәгаләнең бер исеме (үз батырлыгы белән изгелеккә ирешкән каһарман шагыйребез исеменә тап килүе очраклы түгел кебек). Кол Галидә Тәңре нәкъ менә шул исем белән атала. Әсәрдә тасвирланган драматик вакыйгалар да Җәлилнең ихтыяры-магик куәте ярдәмендә хәл ителә. Моның өчен Коръәндәге иң мөһим вакыйга сайлап алына: Ибраһимның үз улы Исмәгыйльне корбан итеп чалу күренеше.

Шушыннан соң вәхи итте ул Хак Җәлил,
Ибраһимга Җәлил әйтте: «Әйа, хәлил,
Минем өчен угылыңны син корбан кыл. –
Тыңлап бакса: – Сөеклеңне», – диде инде.
Тик пычактан Исмәгыйльне кистермәде,
Ибраһимны утка якын китермәде,
һәм Ягъкуб та хакка гөнаһ һич кылмады,
Тәңребездән без дә шулай куркыйк инде.

(Текстлар хәзерге татар теленә Н. Хисамов күчерүендә бирелә.)

Шул арада бу илаһи вакыйга әдәби әсәр кысасына куела һәм Кол Гали каләме белән җир драмасы, анда яшәүче адәм балалары язмышы языла башлый. Ләкин төп мотив шул килеш саклана:

Моны ишетеп Шәмгун бик нык ачуланды,
Пычак тотып, Йосыфка ук каршы барды,
Пычак белән үтерергә дип ташланды,
Моны күреп, Йосыф каһ-каһ көлә инде...

Хәзер инде фашист тоткынлыгында көрәш алып барган җәлилчеләр хакында әйтелә торган «Татарлар елмаеп үлделәр» дигән гыйбарәне искә төшерик. Бу гыйбрәтле күренеш тә Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ндә үзәк мотивларның берсен тәшкил итә. Ул гына да түгел, шул ук пычак-балта астында Хак сынавын үтеп ятучы герой темасы үзәк темаларның берсе булып әверелә:

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә.
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә...

(«Катыйльгә»)

Шул ук тема М.Җәлилнең атаклы «Җырларым» шигырендә дә үзәккә чыга; бу очракта геройның каһкаһәләп көлүе шагыйранә мотив белән алыштырыла.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язына.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла...

Шик юк, әсирлектә чакта М.Җәлил күп мәртәбәләр Кол Галинең атаклы поэмасына – чынлыкта, милләтебезнең рухи-әхлакый-фәлсәфи энциклопедиясенә мөрәҗәгать итә.

Дошманның үз өнендә тоткынлыкны көрәш мәнфәгатьләрендә файдалану идеясе дә «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән килә. Асылда, абыйлары тарафыннан үлемгә хөкем ителгән Йосыф күңелендә кискен көрәш бара: я коллыкка риза булмыйча, һәлакәткә барырга, я коллыкны яшәү, язмыш һәм көрәш хакына кабул итәргә...

Алар әйтте: «Бу коллыкка риза бул син,
Үз телеңнән шулай диеп икърар кыл син... »
Йосыфның җавабы мәгълүм:
«Кол мин» диде, күзләреннән яшьләр акты,
Хуҗа диеп Тәңресен дик уйлый иде...

Муса Җәлилдә дә бу мотив «Кыйссаи Йосыф» рухынча, әмма заман төсмерләре белән хәл ителә:

Белдем микән ирек кадерен
Хөр чагында, дуслар, элек мин?
Тотып авыр коллык җәберен,
Инде белдем тәмен ирекнең!

Шатландырса язмыш күңелне,
Кавыштырып ирек-сердәшкә,
Багышлармын калган гомерне
Ирек өчен изге көрәшкә!

(«Ирек»)

М.Җәлилнең «Кичер, илем!»» шигыре тулысынча диярлек Кол Гали дастанындагы Йосыфның эчке монологын кабатлый: «Үлемгә, – дип, – ачы нәфрәт белән елмаермын соңгы сулышта...»

Яисә: «Өстен килер түбән әсирлеккә үч һәм илгә керсез мәхәббәт...»

Кол Гали әсәренә кабат әйләнеп кайтсак, аны укыган саен Тәңре-Җәлилнең Йосыфны коллыктан коткарачагына ышаныч арта гына бара. Хәтерегездәме, Хак Тәгаләдән, туган иленнән дога өмет итеп тоткынлыкта яшәүче Йосыф бер гарәп кешесен әтисе Ягъкуб янына җибәрә. Гарәп кешесе Йосыфның үтенечен аяк астына салмый, Ягъкуб янына барып, Йосыфның үтенечен җиткерә.

Бу – «Кыйссаи Йосыф» әсәренең кульминация ноктасы.

Нәкъ шушы вакыйгадан соң Йосыфның тоткынлыктан котылу юлы ачыла – гарәп кешесенең үтенече буенча Ягъкуб Аллаһыга дога кыла, һәм Тәңре-Җәлил Йосыфны азат итү чарасына керешә – аңа илаһи төш җибәрә...

Ул арада Җәбраил фәрештә Йосыф катына төшә һәм аның рухын ныгытырдай, азатлыкка, көрәшкә рухландырырдай сүзләр әйтә:

Әйтте аңа: Син шуны бел, әйа сиддикъ,
Дога кылды атаң, сине азат ит, дип,
Тәңре сине азат итә инде тиз, – дип. –
Михнәтләрдән син рәхәткә чыктың инде.

Бу – фашист тоткынлыгында үз-үзен аяусыз көрәшкә багышлаган Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең яшәү рәвеше. Алар әсирлек шартларында да туган җир гаме, сагыну, кавышу хисләре белән яшиләр, якыннарының һәм туган җирләренең аларның көрәшендә һәм җиңеп кайтуында рухи терәк булуына бер тамчы да шикләнмиләр. «Май аенда тагын җыелырбыз» – дип, чын мәгънәсендә күрәзәлек итә М. Җәлил үзенең «Сугыштан соң » дигән шигырендә. Һәм дөрес күрәзәлек итә!

Кол Гали белән Муса Җәлилнең төп язмыш идеясе хакында уйланып карыйк. Йосыф үзен һәлакәткә юлыктырган абыйларына карата, ант итеп, менә ни ди:

Минем әгәр йөз мең җаным булыр ирсә,
Барчасын да сезгә фида кылам инде...

М. Җәлил көрәштәш дусты А.Алишка исә болай дип яза (үзен сугыш афәтенә дучар иткән иле, Ватаны каршында тугрылык саклап):

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне.
Йөзәү булса гомерең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?!

Ә хәзер чагыштырыла торган ике әсәрнең дә образлар системасына җентекләбрәк туктalыйк. Алар арасындагы образлар тәңгәллеге тагын да ныграк гаҗәпләндерә.

Менә Йосыф һәм бүреләр мотивы.
Кол Галидә ул түбәндәгечә яңгырый:
Тик алар (бүреләр. – Г. Г.) *да Йосыфны һич күрмәделәр,*
Тәңре шаһит, Йосыфка үч кылмадылар.
Хакка каршы, сезгә оятлы булмадылар –
Пәйгамбәрлек ите безгә хәрам инде...

Бүреләр кызганып тими калдырган Йосыфны үз туганнары үлемгә һәм әсирлеккә дучар итүләре хакында беләбез инде.

М. Җәлилнең «Бүреләр» балладасы да тулысынча шушы борынгы мотивка багышланган.

Яралының зәгыйфь сулышы
Бәрелде бүренең борнына.
Юк, бүре тимәде, сак кына
Борылып юнәлде юлына...
Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып, якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.
Бүреләр, аһ... ләкин бүреләр
Бу кадәр үк ерткыч түгелләр!..

Бүреләр кызганган яралы батырның тәненә фашистлар кыздырган шомполлар басалар, туйганчы җәфалап, соңыннан ялгыз ак каенга асалар...

Менә шундый гасырлардан гасырларга күчеп йөрүче гыйбрәтле тарих...

Ике әсәр өчен дә бик мөһим һәм принципиаль булган тагын бер мотив бар. Хәтерегездәме: улы Йосыф җибәргән күлмәк белән йөзен сыпырган Ягъкубның күзләре ачыла: «Бәшир килеп шул күлмәкне картка бирде, йөзенә тиреп, күзе кинәт ачылды инде...»

Сагыну, бәхилләү, кабат туганлашу, кавышу мәгънәсенә ия булган бу мотив М.Җәлилдә ике төрле гәүдәләнеш тапкан. «Ана бәйрәме» әсәрендәге мотив Кол Гали әсәрендәге тылсымлы-илаһи тарихка якынрак; ул да туган илендә калган ата-ана сагышының көче белән аңлатыла:

Ана алды алсу байракны,
Күзен сөртте – күзе ачылды,
Каршысында тора гайрәтле,
Киң күкрәкле батыр лачыны!

Икенче очрак исә «Кыйссаи Йосыф»тагы «күлмәк» тылсымы белән турыдан-туры бәйләнгән. Бу мотивны М.Җәлил магик-хыялый шигъриятkә якын торучы баллада жанры кысаларында хәл иткән:

Тыңладылар аны. Сөйгән кызның
Сүзе чындыр кебек күренде.
Һәм күлмәкне илтеп, яшь егеткә
Кидерделәр...
Егет терелде.

(«Күлмәк».)

Сигез гасыр элек яшәгән Кол Галинең шагыйранә рухияте Муса Җәлилнең фашист тоткынлыгындагы иҗатына серле-сихри йогынтысы хакында тагын да тәфсилләбрәк сөйләргә булыр иде. Бу эшне әдәбият галимнәре игътибарына калдырып, шуны гына искәртәсе килә: меңьеллык тарихы булган татар әдәбияты – бербөтен организм ул; аның бихисап күп кан тамырлары белән чорналган йөрәге, мең ел элек ничек типкән булса, бүген дә шулай ук ярсып тибә, үз «аһ»лары белән шулай ук сызлана, тоя, кичерә, сагына, ярата, нәфрәтләнә һәм көрәшә, яшәүгә һәм хакыйкатькә үз юлын даулый, үз хакын хаклый...



17 ИЮЛЬ – БЕРДӘМ ФОЛЬКЛОР КӨНЕ

ЭХ, СӨЛГЕСЕ – керсез күңел көзгесе

Расиха ФАИЗОВА

Арча районы Ташкичү авылында адәм баласын туганнан алып соңгы сулышын алганнан соң да, йоласына туры китереп, озата баручы сөлгене зурлаучы «Сөлгеле капка» ачык фольклор фестивале быел бишенче тапкыр узды.

Фестиваль күптән инде республика чикләрен үтеп, милләттәшләребез яшәгән Оренбург, Самара, Киров өлкәләре, Марий Эл Республикасын да колачлады. Исеме җисеменә туры килә: һәр коллектив үз халкының күңел көзгесе, йөз аклыгы булган сөлгесе белән килә монда. Коллективлар «Халык җыры», «Халык биюе», «Инструменталь башкару», «Фольклор этнографик күренеш» номинацияләрендә чыгыш ясый. Быелгы фестивальдә Татарстанның Әтнә, Алексеевск, Аксубай, Азнакай, Апас, Биектау, Балык Бистәсе, Зәй, Кукмара, Кама Тамагы, Лаеш, Мамадыш, Нурлат, Питрәч, Сарман, Теләче, Югары Ослан, Яшел Үзән районнары һәм Казан үзешчәннәре мәйдан тотты. Аның В.Д. Поленов исемендәге Россия халыклар иҗаты йорты инициативасы буенча уздырылучы Бердәм фольклор көненә туры килүе дә күңелле фал иде.

МӘДӘНИ МИРАСКА ХӨРМӘТ

Сөлгенең чыннан да бәһасе зур. Нинди генә олы эшкә тотынма, йоласы шул дип сөлгегә үреләсең. Сабантуй мәйданына дәшеп колга башында җилфердәүче сөлге белән генә чикләнми әле ул. Элек-электән Сабантуйның баш батырына дип тә, ат чабышында иң соңынан килгән атка дип тә атап чиккән аны кызкыркын. Кыз ярәшкәндә дә ризалык билгесе итеп, кыз ягы сөлге биреп җибәрә. Урам буйлап «Кыз минеке!» дип узучы егетнең кулында да әнә шул вәгъдә билгесе булган сөлге җилфердәгән. Килен төшкәндә, ат дугасына бәйләнгән сөлгенең дә иясе алдан ук билгеле булган: капка ачучы малайныкы анысы.

Ташкичүдә узучы фестивальдә «сөлгеләр парады»на чыккан эшләрнең дә үз миссиясе. Һәркайсының үзенә генә хас осталыгы, бизәге, башкару техникасы. Фестиваль шушы күз нурларын түгеп чиккән сөлгеләре, фольклор җырлары белән генә түгел, ә хуҗаларның кунакчыллыгы белән дә истә калачак. Ни өчен дигәндә, кунак киләсе йортның капкасы да нәкъ менә андагы кебек төбенә кадәр киереп ачылган, урамнан ук тәмле ризык исе таралган булыр. Җитмәсә, йоласына туры китереп капка баганасына чигүле сөлгесен дә элеп куйсаң, кунак-төшемле йорт әллә каян күренеп торачак. Монда да нәкъ шулай! Кунаклар килүгә иртәнге сәгать белән коймагын да пешергәннәр, 100 әр литр сыешлы өч казаннарда пылау да куйганнар. Бәйрәм кунаклары, авылны яңгыратып, нәкъ җырдагыча «урамнар буйлатып, гармуннар уйнатып!» су буендагы сөлгеле капка аша үтеп мәйданга керә. Арча муниципаль район

Фестивальнең Ташкичүдә – электән ата-баба йоласын, гореф-гадәтләрне санлап, саклап яшәүче; Шиһабетдин Мәрҗани, Габдулла Галиев (Батырша), Мәхмүт Галәү кебек шәхесләрнең эзләре калган авылда узуы үзе үк зур нәрсә.

1821–1856 елларда авылда Шиһабетдин Мәрҗанинең әтисе, дин белгече Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани имам-хатыйп булып торган. Булачак илаһият галиме, тарихчы, мәгърифәтче 30 томнан артык фундаменталь хезмәтләр авторы Шиһабетдин Мәрҗани дә башта Ташкичү аннан Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә белем алган. Ташкичүнең 1817 елда нигез салынган мәчете Шиһабетдин Мәрҗани исемен йөртә.

башлыгы, Арча район Советы рәисе Алмаз Гаптрәүф улы Хисаметдиновның кулында да, мәдәният идарәсе җитәкчесе Илфар Илдар улы Әюповның кулында да гармуннар.

– «Сөлгеле капка» ул – халыкның үзеннән килеп чыккан уникаль бәйрәм. Һава торышының явымлы булуына карамастан, бүген 1000 гә якын кунак килде шушы бәйрәмгә. Арча төбәге ул татар теленең, татар дөньясының мәркәзе, бөек Тукаебызның туган җире, сезне үзебездә туристлар буларак та көтеп калабыз,– дип, Алмаз Хисаметдинов килгән кунакларны сәламләде һәм «Сөлгеле капка» алга таба географиясен киңәйтеп иңгә-иң яшәүче төрле милләтләрне берләштерә торган, аларның милли үзенчәлекләрен саклап калуда мөһим урын алучы бик зур бәйрәм чарасына әверелер дигән ышаныч белдерде.

КОЛАЧЛЫ ФЕСТИВАЛЬ

Хәер, Ташкичү авыл Мәдәният йорты директоры Гөлфия Мәгъсумова белән аның сәнгать җитәкчесе Тәнзилә Вәлиевалар башлап йөрмәгән булса, «Сөлгеле капка» гомумән





булыр идеме икән? Яшел Үзән районының Карагуҗа авылында милләтара дуслык, милли мирасыбызны саклауга йөз тотып уздырылган «Куш капка» дип аталган чара этәрә аларны бу эшкә. Озакка сузмый гына, район мәдәният идарәсенә: «Әйдәгез, Ташкичүдә гореф-гадәтләр, йолалар, сөлге, чигү үрнәкләре белән бәйләп фольклор фестивале оештырыйк»,– дигән тәкъдимнәрен җиткерәләр. Фестиваль программасына чигүле сөлгенең килеп керүе дә очраклы түгел.

– Ташкичүдә элек-электән халык һөнәрчелегенең келәм, паласлар туку, чыпта сугу, сөлге-тастымаллар чигү, бау ишү кебек төрләре киң таралган була. Чигүчелек кәсебе бүгенгәчә дәвам итеп, авыл Мәдәният йортында да «ТатАрча бизәкләр» дигән түгәрәк эшләп килә. Анда безнең «Өммегөлсем» фольклор коллективына йөрүче ханымнар (җитәкчесе Тәнзилә Вәлиева) яшь кызларны чигү серләренә өйрәтәләр. Ул безнең Татарстан Мәдәният министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырылучы «Мәхәллә» проекты кысаларында алып барыла. «Сөлгеле капка»га килсәк, ул беренче елында ук зур резонанс уятты һәм бүгенгәчә рухи мирасыбызны барлап, шуларны бер мәйданга чыгарып киләчәк буыннарга җиткерүдә максатчан эшли. Коллективлар очраша, аралаша, тәҗрибә уртаклаша. Дуслык бәйрәмендә безнең барыбызны да сөлге берләштерә,– ди Арча районы мәдәният идарәсенең сәнгать җитәкчесе Ләйлә Мөхәммәтгалиева.

Фестивальдә беренчеләрдән булып чыгыш ясаучылар да – «Өммегөлсем» халык фольклор коллективы булды. Аларның җитешмәгән җирләре юк. Әле күптән түгел Илһам Шакиров турындагы «Илһам» өч серияле фильмында күмәк күренешләрдә катнашучылар арасында иделәр. Тәвәккәл таш яра, дип тә нәкъ менә Гөлфия Мәгъсумова белән Тәнзилә Вәлиева кебекләргә әйтәләр. Алар – бронежилетлар киеп, гуманитар ярдәм төялгән машина белән махсус хәрби операция барган зонада алгы сызыкка кадәр барып җитеп, ун көн дәвамында Биектау, Әлмәт, Чүпрәле, Яшел Үзәннән киткән егетләр белән күрешеп, кыр госпитальләрендә булып кайткан ханымнар. Мондый сынауларны үтеп кайтканнан соң яшәргә көч, дәрт бирүче «Сөлгеле капка»ны гына үткәрә дә үткәрә инде алар.

– Быел район хакимияте, чыгымнарны үз өстенә алып, бик булышты. Туй килә дип тун тегелә – кунаклар килүгә, Мәдәният йорты алдына асфальт та җәелде. Авылдашлар да канәгать, килгән кунаклардан да әле булса рәхмәт сүзләре ишетәбез,– ди Ташкичү авыл Мәдәният йорты директоры Гөлфия Мәгъсумова.

Татарын, русын, керәшенен, мариен, удмуртын, чувашын бер мәйданга туплаган фестиваль көн дәвамында гөр килде. Халык җәүһәрләрен – фольклор җырларны, онытыла бара торган борынгы йолаларны торгызу бәрабәренә фестиваль елдан-ел җәтеләнә бара.

Иң мөһиме, фестиваль коллективларны эзләнергә этәрә. Фестивальгә икенче тапкыр гына килүенә карамастан, Киров өлкәсенең Нократ Аланы шәһәренең «Кояш» татар җыры халык ансамбле җитәкчесе, оештыручысы Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рәйсә Мөхәммәтшина да шул фикердә. Аларның гармунсыз гына башкарылган борынгы Шушма көен тыңлагач, чыннан да «көймәләрнең түренә утырып» елга буйлап акрын гына йөзеп баргандай буласың. Фестивальдә ул беренче тапкыр яңгырады. Өсләрендәге Нократ татарларына хас күлмәкләрне исә музей экспонатларына таянып теккәннәр.

– 15 кешене берләштергән коллективыбызның оешуына быел 18 ел. Безгә юлны заманында «Түгәрәк уен» фольклор фестивале ачты, безне ул үстерде. 2012 елда Самарада узган V фестивальдә катнашканнан соң фольклорның нәрсә икәнен чын-чынлап аңладым. 2013 елда дүрт кеше Киров өлкәсенең Слободской районында яшәүче Нократ татарларына – Карина дигән авылга экспедициягә киттек. Аннан җыеп кайткан материалны файдаланып, «Килен сөлгесе» дигән номер эшләдек. Малмыж районына экспедициягә баргач, керәшеннәрнең онытылып беткән җырларын алып кайттык. Эзләнмичә генә, өйрәнмичә генә булмый, шуңа күрә дә әлеге фестивальдә бик теләп катнашабыз, – ди ул.

Казанның Мирный бистәсендә эшләп килүче шәһәр Мәдәният йортлары арасында бердәнбер халык фольклор ансамбле булган «Җәүһәр»нең җитәкчесе Ләйлә ханым Сафиуллина да үзенекеләрне мактый. «Җырлап кына йөргәч, безнең картаерга һич вакыт юк. Ансамбльдә иң өлкәнебезгә 82, 85 яшь. Кайда гына чыгыш ясамыйбыз, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә «Каз өмәсе» дисеңме, «Карга боткасы»мы, «Аулак өй», «Кичке уен» күренешләрен һәммәсен күрсәтәбез. Борынгы җырларыбыз, йолаларыбыз онытылырга тиеш түгел. Өлкәннәр пансионатларында да безне көтеп алалар. Күптән түгел Милли китапханәдә үзебезнең ансамбль солисты Наил Исмәгыйлевнең китабын тәкъдим итүдә катнаштык. Ул һади Такташның шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итте, – дип сөйләп китте ул үзләренең көндәлек мәшәкатьләрен бер җепкә тезгәндәй.

Татарстан белән чиктәш булып, тел, лөгать алмашып гомер итүче Мари-Төрек районының Сардаял авылыннан килгән фольклор төркеме солистлары үзләренең милли киемнәре белән әллә каян аерылып торалар. Ызандаш булып яшәгән татар авылы Пешәңгәр үзешчәннәре белән бер сәхнәдә концертлар да куялар икән. «Шулай булмый җае да юк, без бер-беребезне якыннан беләбез, аралашабыз, араларыбыз нибары 2 чакрым гына», – ди Сардаял Мәдәният йорты җитәкчесе Татьяна Сорокина.

Катнашучылар арасында өлкән яшьтәгеләр күпчелекне тәшкил итсә дә, Арча районы Шура авылы кызлары Рәдинә, Рәйсә, Ләйсән, Фирүзә кебек югары сыйныф укучылары, студентлар да юк түгел (җитәкчеләре Клара Хөсәенова).

Аксубай районының Мюд бистәсендә 15 ел дәвамында эшләп килүче «Ялкын» ансамбленең (Роза Байдуганова), Теләче районы Үзәк совхозының «Нурлы яз» коллективының (Элина Тарасова) фестивальдә беренче генә катнашулары, шулай да инде «Сөлгеле капка»ны яратып өлгергәннәр: «Безгә монда бик ошый, күңелдә кала торган бәйрәм, күп кенә коллективлар белән таныштык, аралаштык, дуслаштык». Хәер, кем белән генә сөйләшсәң дә, шул ук сүзләрне кабатлаячак. Димәк, оештыручылар үз дигәннәренә ирешкән дигән сүз. Шулай да Арча муниципаль район башлыгы Алмаз Гәптрәүф улы Хисаметдиновның фестивальне киләсе елларда тагын да зуррак мәйданнарга күчерәсе килү нияте генә бераз сагайткан ташкичүлеләрне. «Сөлгеле капка»ның үзебездә, Мәрҗани эзләре калган авылның мәрҗәне, йөзек кашы булып калуын телибез, диләр алар.

Автор фотолары

«АРЧА ЧИТЕКЛӘРЕ» милли мирас сагында

Гөлнур МИННЕБАЕВА,
Арча



Арча төбәге тарихын барлаганда иң якты сәхифәләренең берсе – һичшиксез, милли аяк киемнәре, аеруча татар читекләре җитештерү тарихы. Күп еллар элек Арчада эшләгән фабрика бүген инде юк, әмма аның осталары тудырган гүзәллек Россиянең һәм дөньяның төрле музейларында саклана. Милли сәнгатьнең бу кыйммәтле мирасы «Арча читекләре» этнофестивалендә үзенең дәвамлы булуын, яшәвен дәлилләде.



ФЕСТИВАЛЬНЕҢ ДӘРӘҖӘСЕ АРТА

«Арча читекләре» фестиваленең башлангычы Кылачы авылына барып тоташа. Бу очраклы түгел. Нәкъ менә Кылачы милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе аның чишмә башы булып тора. Биредә яшәүчеләр күнне бизәкләп эшләү технологиясен беренчеләрдән булып үзләштергән һәм бу һөнәрне киң җәелдергән. Арча милли аяк киемнәре җитештерү тарихы XIX гасыр ахырыннан башлана дибез икән, Кылачы авылы кешеләренә каян килгән соң бу осталык, дигән урынлы сорау туа. Ул болайрак: 1885 елда Рамазан һәм Вәли Гайнуллиннар эш эзләп, Казанга китеп, читекләр әзерләүче Солтан байга ялланалар. Ике ел эчендә алар бу һөнәрнең нечкәлекләрен үзләштереп, туган авылларына кайталар һәм башка егетләргә дә Казанга барып эшкә урнашырга ярдәм итәләр. Нәтиҗәдә 1925 елга кадәр Кылачының дистәләгән кешесе Казанда милли аяк киемнәре җитештерүдә хезмәт куя.

* * *

Ике ел элек Кылачы авылында район күләмендә уздырылган «Арча читекләре» этномәдәни фестивале быел Арчаның үзәк стадионында республиканың иҗади коллективлары катнашында узды. Бәйрәмгә килүчеләрне капка төбеннән үк «Хәзинә» фольклор коллективы Арчаның читек белән бәйле тарихи үткәнен – Кылачы авылыннан башлап Арча «Милли аяк киемнәре җитештерү» берләшмәсенә кадәр узган юлны чагылдырган театраль күренеш белән каршы алды.

– Арчаны читексез, читекне Арчасыз күз алдына китереп булмый. Читекнең гасырдан артык тарихы Арча белән бәйләнгән. Озак еллар читек фабрикасында эшләгән абый-апалар бүген безнең арада. Алар эшләгән еллары турында горурланып сөйлиләр, – ди Арча муниципаль районы башлыгы Алмаз Хисаметдинов һәм төбәктә шундый матур традицияне булдырганнары, саклап калганнары өчен рәхмәтләрен җиткерде. Бәйрәмне тагын да масштаблырак итү нияте дә юк түгел Алмаз Гаптрәүф улының.

ТАРИХКА КҮЗ САЛСАК...

1929 елда кооператив артельләр оештырыла башлый. Арча районындагы беренче артельне Кылачыда ачарга ниятләсәләр дә, тиешле бина булмау сәбәпле, биш чакрым ераклыктагы Мүлмә авылындагы элекке хәрби казарма сайлана. Артельгә «Тукай» исеме бирелә. Кылачыдан 120 кеше көн саен Мүлмәгә йөреп эшли.

Читек җитештерү күләме үскән саен, өйдә эшләүче чигүчеләр саны да арта. Һөнәрчеләрнең саны кайбер елларда 750 гә җитә. Кылачы, Урта Аты, Урта Сәрдә осталары әзерләгән милли аяк киемнәре чит илләргә дә чыгарыла. Кылачы осталары чиккән читекләр Һиндстан Премьер-министры Индира Гандига, туфлилар Надежда Крупскаяга бүләк итеп җибәрелә.

1930 еллар татар милли аяк киемнәре җитештерүнең чәчәк аткан чоры.

1941 елда «Тукай» артеленнән аерылып чыгып, Кылачыда «Труд» артеле оеша. Сугыш елларында биредә фронт һәм госпитальләр



өчен аяк киемнәре тегелә. Сугыштан соң чимал җитмәгән чорларда солдат пилоткаларыннан хатын-кызлар өчен җиңел аяк киемнәре тегәләр.

1946 елда «Труд» артеле күчмә Кызыл Байрак белән бүләкләнә.

1960 елда артель фабрика статусын ала. 1961 елда аңа Мүлмә, ә 1962 елда Дөбьяз фабрикалары кушыла.

1972 елда Арчада фабрика өчен ике катлы яңа бина төзелә. Производство «Милли аяк киемнәре җитештерү» берләшмәсенә әверелә.

1970 еллар ахырына филиалларны да кертеп, берләшмәдә 1200 гә якын кеше хезмәт куя. Көненә 550–570 пар аяк киеме җитештерелә.

1980 елда Лейпциг ярминкәсендә (Германия) Арча берләшмәсе продукциясе алтын медальгә лаек була.

2006 елда икътисади кризис аркасында «Милли аяк киемнәре җитештерү» АҖ эшчәнлеген туктата.



Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге методисты Миләүшә Насыйбуллина исә елдан-ел фестивальнең дәрәҗәсе үсүен ассызыклап үтте. Читекне саклаучы, милли бизәкләрнең дәрәҗәсен күтәрүчеләргә соклануын җиткерде.

Күргәзмәләрдә милли рухның бүгенге көндә ничек саклануын күрсәк, «Казан арты» музее һәм райондагы Мәдәният йортлары хезмәткәрләре районда күн эшкәртү тарихы, күннең төрләре, элеккеге артельләрнең эшчәнлеге һәм милли аяк киемнәре фабрикасының бай мирасы белән таныштырды. Читекләрдәге бизәкләрнең үзенчәлеге, аларны ясау ысуллары, озак еллар бу өлкәдә хезмәт куючылар белән очрашу, «Казан җәе» буенча осталык дәресләре – һәммәсе фестиваль кунакларында кызыксыну уятты.

ОСТАЛАР – СӘХНӘ ТҮРЕНДӘ

Бәйрәм сәхнәсендә Арча, Әлмәт, Алексеевск, Әтнә, Биектау, Балтач, Сарман, Кукмара, Кама Тамагы районнарыннан, Казан шәһәреннән килүче һәвәскәрләр «вокал», «инструменталь башкару», «хореография», «фольклор-этнографик күренеш» номинацияләрендә үз осталыкларын күрсәтте.

Фестиваль кысаларында оештырылган «Читегемне күрегез» дип аталган кул эшләнмәләре бәйгесенә дә нәтиҗә ясалды. Читекләрнең иң үзенчәлекле дигән дүртесе югары бәяләнде. Шулай итеп, беренче дүрт урынны Арчадан Зифа Вәлиева, Яңа Кенәрдән Лилия Фазылҗанова, Әлмәт районы Бишмунча авылы Мәдәният йортыннан «Мәдинәкәй» халык фольклор ансамбле һәм Арча районы Ашытбаш авыл Мәдәният йорты хезмәткәрләре бүлеште. Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Кече мәйданда район һөнәрчеләре үзләренең эшләнмәләрен тәкъдим итте. «Арча читекләре» фестивале милли мирасны саклау – үткәнне искә алу гына түгел, ә бүгенге көндә без аны яшьләргә ныклап өйрәтеп, киләчәк буынларга тапшыруны күз уңында тотарга тиешлегебезне искәртә.

Земфира Рамазанова фотолары



Каюлы күнне дөньяга танытып

Гүзәл ХӘМЗИНА

Казанның халык сәнгате һөнәрләре техникумында производствога өйрәтү мастеры Гөлия Наил кызы Сафина турында сүз чыкканда, аның Алия Фаздалова (Арча), Мәдинә Сәгытдинова, Розалия Новикова (Казан), Рәмзия Галимҗанова (Кукмара) кебек инде мөстәкыйль рәвештә эшләүче шәкертләрен дә искә алып үтми калмыйлардыр.

«Казан җөе»нең кабатланмас матурлыгын, башкару техникасын үзебезнең республика, Россия күләмендә генә түгел Катар, Казахстан, Төрекмәнстанда да күрсәтелде. Грозныйда узган «Многоликая Россия» конкурсында «күн эшләнмәләр» номинациясендә I урынга, халык һөнәрчеләренең «Саумы, Казан» бәйгесендә акчалата премиягә лаек булган останың эшләре әле күптән түгел генә Казанның Уникаль осталык үзәгендә «Тормыш стиле – мәдәни код» этнофестивале кысаларында узган Күн сәнгатенең халыкара фестивалендә дә тәкъдим ителде. Күтәреп алынмаган җыр – җыр түгел, диләр. Каюлы күн дә күңелгә үзгә бер җылылык, наз өсти торган җыр шикелле. Аның шундый сихри көчкә ия булуын Россиянең төрле төбәкләреннән әлеге этнофестивальгә килгән күнчеләр дә тиз төшенде. Шулай булмаса, Гөлия ханымның осталык дәресләреннән соң үзләре белән алып китәргә дип, «Казан җөе» станын эзләп йөрерләр идеме?

* * *

«Казан җөе»нең ничек эшләнүен, технологиясен белми торып, милли бизәкләр төшерелгән читек, чүәкләрдәге бизәкләрнең эшләнешен аңлавы кыен. Чыннан да гадәти җөй генә түгел ул. Монда ике төрле җеп «эшли». Аның



Гөлия Сафина Күн сәнгатенең халыкара фестивале кунакларына күн эшләнмәләрен тәкъдим итә

берсе төп ефәк җеп, икенчесе декоратив (орчык белән катылган төрле төсләрдәге җепләр). Аны эчке яктан яшерен җәй белән тегелә торганы белән дә, тышкы якта калдырып тегелгән җәй белән дә чагыштырып булмый. Ул – уникаль. Ике төрле күнне кара-каршы китереп «үбеш-тереп» куясың да, үзенчәлекле декоратив җәй шул кисәкләрне тоташтыручы ролен дә үти, бер үк вакытта бизәк тә. Шунысы мәгълүм: татарларга гына хас бу техникада бер генә халык та эшләмәгән.

Гөлия ханым әлеге эшнең асылына олпат остазыбыз Илдар ага Шәйхетдиновтан өйрәнә. Тора-бара халык иҗатына гашыйк ханымның аягында үз кулы белән чигелгән бизәкле итекләр, кулында шундый ук сумкалар күренә башлый. 22 ел банк системасында эшләгәннән соң, биш ел дәвамында кооперация техникумында «банк эше»н укыткан ханым көннәрдән бер көнне барысын читкә куя да, тәвәккәлләп Казанның халык сәнгате һөнәрләре техникумына укырга керә.

Әлки районы Алпар авылында яшәүче Рабига әбисенең нәрсәгә тотынса, шуны коеп куя торган оста икәнен дә кечкенәдән күреп, белеп үсә кыз. Күннән төрле билбаулар, иләнгән сарык тиресеннән, намаз укыганда гына кияр өчен, дип йомшак башмаклар тегүче дә ул бит. Күнне дә ят итми әбиләре. Әлеге чималны оныклары кулына тоттырганда да: «Күнне бер вакытта да кайчы белән кисмәгез, ул аны сөймәй, бары тик пәке генә кулланыгыз», – дип, ул шул чагында ук колакларына киртләп куя.

Остазы Илдар аганың киңәшләрен дә онытасы түгел: иң беренче чиратта эш урыны уңайлы булырга тиеш, дип өйрәтә ул.

– Хәзер станокларның заманча, җиңеләйтелгән вариантлары да бар, әмма элеккеге осталарныкына җитми, чөнки ул һәрьяклап уйланылган. Монда күз белән кул арасы да (20 см), гәүдәне төз итеп тоту да исәпкә алынган, – ди Гөлия Сафина.

Гөлия ханым остазының кайбер сыйфатларын үрнәк итеп алмый калмагандыр билгеле, чөнки бүген аның үзен дә бу эшнең бар нечкәлеген белергә омтылучы яшьләр сырып алган.





1.



2.

Эш өчен безгә түбәндәгеләр кирәк булачак:

– станок (стан), ул булмаса урындык башы ярдәмгә киләчәк,
– өлге буенча киселгән (икесе ике төстәге) күн кисәге,
– орчык белән катылган төрле төстәге чигү җепләре (мулине яки яхшы юылуын һәм кояшта уңмавын истә тотып лавсан). Җепне күн төсенә яраклаштырыбрак сайлау зарур,
– сапка беркетелгән без һәм тегү машинасы энәсе.

Эш барышы:

Иң башта, әлбәттә, булачак бизәкне кәгазьдә ясыйбыз. Аны катыргыга күчереп трафарет-өлге ясыйбыз. Өлгене күн өстенә куеп карандаш белән төшергәннән соң, үткен пәке белән кисәбез (мөгезле эре терлек яки кәҗә тиресеннән эшләнгән күндә бизәк матур чигелә).

Ике төсле күнне станда кара-каршы китереп сул ягын өстә калдырып урнаштырабыз. Төшеп китмәсен, тотрыклы булсын, шуып йөрмәсен дип, аны кереш яки каеш белән тарттырып бәйләп куябыз.

Җәй белән җәй арасы бер миллиметрдан да зур калмаска тиеш.

Энәне күнгә чәнчибез һәм тишеп чыккан энәгә декоратив җепне өч кат урыйбыз да җепнең очын кулга алабыз. Җеп чорналган энә белән каршы яктагы икенче күннең уң ягыннан (аскы яктан) тишеп чыгарабыз һәм энәне чак кына артка чиктерәбез. Бу вакытта энә астында асылынып торган җеп күренә һәм без шул арага энәне кертеп, ике яктагы җепне дә берьюлы сак кына тартып ныгытабыз. Алга таба эш шул рәвешле дәвам итә.

Бизәк ничек кенә катлаулы булмасын бөтен эш әлеге станок өстендә башкарыла. Соңыннан бизәкне салдырып, арткы ягын чак кына юеш чүпрәк белән ышкып, рамга тарттырабыз. Болай иткәч, ул тигезләнеп, кирәкле форманы ала.



3.



5.



4.



6.

Автор фотолары

Зәмзәмия ЗӘЙНУЛЛИНА,
Балык Бистәсе районы, Иске Арыш авылы Мәдәният йорты җитәкчесе



«Изгеләр ашы»

БАЛЫК БИСТӘСЕ РАЙОНЫНЫҢ 900 ЕЛЛЫК ТАРИХЫ БУЛГАН ИСКЕ АРЫШ АВЫЛЫНДА БИК КҮРКӘМ ЙОЛА ЯШӘП КИЛӘ: ЕЛНЫҢ-ЕЛЫНДА ИЮНЬ АЕНЫҢ СОҢГЫ ҖОМГАСЫНА «ИЗГЕЛӘР АШЫ» ТӘГАЕНЛӘНӘ. АНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ – КОРЪӘН УКЫП ИЗГЕЛӘР РУХЫНА, НӘСЕЛЕҢДӘ БУЛГАН ӘБИ-БАБА РУХЫНА ДОГА КЫЛУ. ИЗГЕ ЧИШМӘ ЯНЫНДАГЫ БОЛЫНЛЫКТА ҮТҮЧЕ ӘЛЕГЕ ЙОЛА ХӘТТА СУГЫШ ЕЛЛАРЫНДА ДА ӨЗЕЛМӘГӘН.

ЯХШЫ НИЯТ – ЭШ БАШЫ

Авыл халкы аны әлегәчә өстә торган игелекле гамәл буларак кабул итә һәм анда катнашуны үзенең бурычы саный. Авылдан күптән чыгып китеп, читтә яшәүчеләр дә, туган туфракка баскан эзен суытмыйча «Изгеләр ашы»на туры китереп, ата-баба нигезенә кайтырга тырыша. Быел исә тоташ явым-төшемгә киткәч, аксакаллар бергә җыелып киңәш-табыш иткәннән соң аны июльнең беренче җомгасына күчерергә ният кылдылар. Һәм ул гадәттәгечә ихлас күңелдән әзерләнеп, олысы-кечесенең хәтерендә мөһим бер вакыйга булып уелып калырлык итеп уздырылды.

Әлбәттә, бердәмлек, әзерлек таләп итә торган бу эшнең электән килгән үз тәртибе бар.

Аш уздырыласы, табыннар корыласы аланны, чишмә буйларын, зират тирәләрен җыештыру эшләре атна ун көн алдан ук башлана: үләннәре чабыла, утын хәстәрен кайгырталар, башка шәһәрләрдә яшәүче авылдашлар белән интернет аша аралашу активлаша... Табын корып утыруның үз тәртибе: көндезге якта хатын-кызлар, кичен ир-атлар җыела. Киенү әдәбе, ягъни дресс-код та сакланырга тиеш. Чәч-баш туздырып, кыска итәктән йөрисе түгел, өстә озын итәкле күлмәк, башта яулык булу шарт. Билгеле инде анда баргач, мәгънәсез сөйләшүләрдән дә тыеласың.

ИЛ – ИРГӘ, ИР ИЛГӘ ТАЯНА

Изгеләр рухына дога кылу дип әйтү билгеле буш урында барлыкка килмәгән. Авылда өч зират. Аның хәзерге дигәненә дә 200 еллап булыр диләр. Аннан башка борынгы дип йөртелгәне һәм изгеләр каберлеге бар. «Изгеләр ашы» йоласы зираттагы әрвахлар турында халык хәтерендә сакланган риваятьләргә нигезләнә. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән риваятьләргә караганда изгеләр каберлегендә

Һәр нигезнең, һәр авылның,
Һәр каланың үткәне бар...
Гыйбрәт алырлык мирасның
Калганы бар, киткәне бар.

Равил Фәйзуллин





туган туфракны саклап шаһит киткән яугирләр җирләнгән. Шунда ук бераз читтәрәк нарат һәм чыршы агачлары үсеп утырган каберстанда исә Явыз Иван гаскәрләренә каршы сугышкан изге җайдаклар күмелгән диләр. Патша гаскәрләре авылны басып алмакчы булган. Тик ап-ак киемнәрдән киенгән сугышчылар аларга каршы чыгып, авылны бу афәттән саклап калган.

САВАПЛЫ ГАМӘЛ

Болай да иртәчел авыл халкы аш уздырыласы көнне тан әтәчләрен дә уздыра. Иртәнге алтыларда садака итеп бирелгән сарык һәм кош-кортлар өчен дога кылдырып, аларны Аллаһ ризалыгы өчен атап чалганнан соң, ир-атлар, гадәттәгечә ил-көнгә иминлек, тормышыбызга бәрәкәт тели-тели казан асып, аш пешерү эшенә керешәләр. Ризык әзерләү ул көнне тулысынча ир-атлар җилкәсендә. Елның-елында шеф-повар вазифасын Хөрмәт абый Закировка йөкләләр. Гомумән Илдар, Булат Зәйнуллинар, Сәгытдин Хәйруллин, Роберт Габделкәбиров, Равил Ибәтов, Салават Имамиев, Альберт Гыйльметдинов кебек иртәнге сәгать белән мал чалуда, аш пешерүдә ихластан ярдәм итеп эш башлап йөрүчеләр байтак була ул көнне. Билгеле, хатын-кызлар да читтә калмый. Кайсысы тавык йолкый, кайсысы табын кору хәстәрен күрә. «Изгеләр ашы»на атап, хәер итеп алып килгән суган, кишер, бәрәңге, токмач, ярма кебек нәрсәләрнең һәркайсына абыстайдан аерым-аерым дога кылдыргач, күчтәнәчләр пешекчеләр карамагына күчә. Күрше авыллардан килүчеләр дә буш кул килми. Һәммәсе азарынып садакаларын тапшыралар. Авылның абыстае тугызынчы дистәсен түгәрәкләгән Зөләйха Сафиуллина янындагы халыкны карап торсаң, анысы үзе бер могҗиза: мондый чиратны кайда күрәсең тагын?!

Саваплы аш дүртәр-бишәр урында пешә. 250 шәр литр сыешлы тәпәннәргә дүртәр сарык түшкәсе салына. Авыл халкы быел корбанлык өчен 31 баш сарык, 48 баш тавык китергән.





Күз алдына гына китерегез, бу бит түшкәне эшкәрткәннән соң болынлыкта бер-бер артлы 31 сарык тиресе җәеп салынган дигән сүз. Аның саны 51 гә җиткән еллар да бар.

Юкка гына ир-ат пешергән ашка фәрештә канатын тыга, димиләрдер. Озак та узмый, тәмле шулпа исе бөтен болынга тарала. Сәгать уннар тулуга ул инде пешеп тә чыга, ләкин әле ашарга утырырга ашыкмыйлар. Өйлә намазы җитәрәк, вәгазьләр сөйләнә, догалар укыла һәм һәммәсе рәт-рәт тезелеп кыйбла ягына йөз тотып, намазга баса. Намаз укылып бетеп, табын-табын булып урнашуга, аш, ит китерәләр. Авыру сәбәпле бу чарада катнаша алмаучылар да өлешсез калмый. Авылдашлар ашны аларның өйләренә илтеп бирү җаен таба.

Кичке бишләр тирәсендә ир-атлар җыела. Кичке табыннар саны 150–160 ларга җитә хәтта. Монда да шулай ук вәгазьләр сөйләнә, изгеләр рухына, ата-баба рухына багышлап авылның мулласы Ринат хәзрәт Габдуллин тарафыннан Коръән укыла.

– Бу йоланың кайчан башлануын берәү дә төгәл генә әйтә алмый. «Изгеләр ашы»на кечкенә вакытта кичен көтүләр кайтып, мал-туар абзарга керүгә, әтиләргә ияреп бара торган идек. Ул чакларда, халык күбрәк җәяү, я булмаса атлар белән барыр иде. Хәзер күпчелек машиналарда киләләр. Аллаһы Тәгаләгә мең шөкер, кылган гамәлләребез, укыган догаларыбызның хикмәте, әҗере әйтеп бетергесез. Авыл халкының табигать афәтләре – җил-давыл, гарасат ише зәхмәтләрдән бервакытта да зыян күргәне юк, – ди Ринат хәзрәт.

Чыннан да без – «Изгеләр ашы»ның мәгънәсен, аның телеңне йотарлык шулпасының тәмен кечкенәдән белеп үскән кешеләр. Шуңа күрә дә кендек каныбыз тамган җиребезгә генә хас бу йоланың асылын югалтмыйча, бездән соң килгән буыннарга да аны түкми-чәчми тапшырырга бурычлыбыз.

Фотолар авторның шәхси архивыннан



Күлмәк котлау

(Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен шөгыль)

Тәрбияче. Исәнмесез, балалар! Бүген без, сезнең белән матур күлмәкләребезне киеп, күчтәнәчләр алып, кунакка барырбыз!

(Тәрбияче балаларның игътибарын җиһазланган уен өстәленә юнәлтә.)

Кунакка барганда нинди күчтәнәчләр алырбыз икән? *(Балалар өстәлдәге татар халык ашларын сайлап-сайлап, кәрзингә сала баралар. Кем нәрсә салганын әйтә.)*

Балалар. Чәкчәк, урама, өчпочмак, пәрәмәч...

Тәрбияче. Бүген Ләйлә яңа күлмәк кигән икән. Ә безнең татар халкында яңа киемне котлау гадәте бар. Әйдәгез, Ләйлә уртага чыксын, без аның күлмәген котлыйк әле.

«Күлмәк әйләнәсе» уены *(түгәрәк уртасында яңа кием кигән бала чыга).*

– Без барабыз кунакка, *(атлыйлар)*
Котлы булсын күлмәгең! *(кул чабалар)*
Бигрәк матур бизәгең! *(күлмәгенә күрсәтәләр)*
Әйдә бергә биибез! *(кул чабалар)*

Ләйлә.
Өстемдәге күлмәгемә
Күпләр карый сокланып.
«Кем текте?» – дип, кайберләре
Сорап куя тукталып.

Әнием, дим, әнием минем –
Фабрикада тегүче.
Бер мин генә түгел әле
Ул теккәнне киюче.

(Әнәс Кари)

Тәрбияче. Рәхмәт, Ләйлә. Балалар, кием котлаганда нинди сүзләр әйтүе урынлы булыр икән? (Мактау сүзе, соклану сүзе, иң матур теләкләр.) Хәзер мин, Ләйләнең күлмәген котлап, матур сүзләр әйтәм, ә сез кабатлагыз һәм исегездә калдырыгыз.

– Ләйлә, күлмәгең бик матур!
– Ләйлә, күлмәгең котлы булсын!
– Ләйлә, күлмәгең бик килешә үзеңә!
– Күлмәгеңнең бизәкләре бигрәк матур!
– Күлмәгеңнең төсе бик тә килешә үзеңә!

Тәрбияче. Балалар, без тагын нинди киемнәрне беләбез?

Балалар. Чалбар, башлык, туфли, яулык, алъяпкыч, читек, калфак...

Тәрбияче. Ә хәзер без түгәрәккә басып уйнап алыйк! Котлау сүзләреннән «матурлык чылбыры» ясыйк. Минем кулымда күлмәк «бизәге». «Бизәк» кемнең кулында кала, шул Ләйләнең күлмәген котлый.

Балалар.
Күлмәккә бизәк салабыз,
Кемдә икәнен табабыз!
Бизәк, бизәк, йөгереп чык!

(Тәрбияче музыка уйнап торганда түгәрәктә торган балаларның учларына бизәкне «салып йөри» һәм сиздермичә генә бер баланың учында калдыра. Бизәк тоткан бала күлмәк котлый.)

Ләйлә. Рәхмәт, дусларым! Күлмәк котлату бик күңелле икән.

Тәрбияче. Ләйлә, безгә иң яраткан шигырьләреңнең берәрсен сөйләп бир инде.

Ләйлә. «Чибәр күлмәк».
Зәңгәр күлмәк, ал күлмәк,
Нинди матур бу күлмәк!
Киеп кара, әйләнеп,
Калырсың син сокланып.
(Әхмәт Рәшитов)

Тәрбияче. Карагыз әле, балалар, безнең котлаулардан соң Ләйләнең кәефләре ничек күтәрелеп китте! Әйдәгез, бергәләп биеп тә алыйк.

Күмәк бию «Шома бас».
Дидактик уен «Сандыктан кием сайла».

Тәрбияче. Балалар, менә бу сандыкта нинди генә киемнәр юк. Әйдәгез, мин аларны сандыктан чыгара барам, ә сез нәрсә икәнен әйтә барыгыз. *(Балалар бергәләп җавап бирәләр: калфак, читек, алъяпкыч, түбәтәй...)*

Тәрбияче. Балалар, әгәр дустыгыз яңа түбәтәй кисә, сез аңа нәрсә диярсез?

Балалар. Түбәтәең котлы булсын!

Иҗади эш

Тәрбияче. Әйдәгез, курчакларыбызга да яңа күлмәкләр «кигертәбез».

(Балаларга кәгазьдән киселгән күлмәк үрнәкләре бирелә. Алар әзер бизәкләрне күлмәккә ябыштырып бизиләр.)

Тәрбияче. Балалар, без бүген нәрсә турында сөйләштек?

Балалар. «Күлмәк котлау» турында.

Тәрбияче. Кием котлаганда нинди матур сүзләр әйтәбез? *(Балалар җавап бирә).*

Ләйлә. Күлмәк котлаганда бүләк, күчтәнәч алу да күңелле. Дусларым, әйдәгез, күчтәнәчләр белән бергәләп чәй эчик! *(Ләйлә балаларга чәкчәк өләшә.)* Бергәләп чәй эчәләр.

Илгизә ГАЛИЕВА,
Азнакай шәһәренең катнаш төрдәге 14 нче «Родничок» балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе,

Гөлнара ИХСАНОВА,
татар теле тәрбиячесе



Планеталар

Эльмир Низамов
Резедә Гобаева сүзләре



Баш өстендә күк йөзе,
Шундый серле ул үзе!
Яши анда кометалар,
Йолдызлар, планеталар!

Әйдә бергәләп саныйк:
Кемнәр белә – кушылыйк!
Ничә планета күктә?
Серле күк безне көтә!

Җир, Юпитер һәм Сатурн,
Меркурий, Марс, Уран!
Венера, аннан Нептун,
Соңгысы була – Плутон!

Берсе аның безнеке –
Без әлбәттә – Җирнеке!
Барлыгы тугыз алар –
Сер тулы планеталар!

Карабодай БӘЛЕШЕ

Гүзәл ХӘМЗИНА

Сезнең карабодай чәчәк атканда басуга чыкканыгыз бармы? Ул һич арттырусыз дулкын-дулкын булып җилдә тибрәнүче ак диңгезне хәтерләтә, ә андагы хуш исне сүз белән генә дә аңлатып бетереп булмас. Дөньяның бар мәшәкатен калдырып, әлеге хозурлыкны күрергә никадәр иртәрәк чыгарга тырышма, син инде барыбер соңарган буласың, чөнки бал кортлары басу белән умарталык арасын сиңа кадәр 100 кат урарга өлгергән булыр... Шуңа күрә дә без карабодай бәлеше дигәнгә караганда карабодай балы дигәнне ешрак ишетәбез булса кирәк.

Матурлык белән алдырган карабодай өстәвенә бик файдалы да. Иң беренче чиратта ул аксымга, майларга, Р һәм В төркеме витаминнарына бай. Анда тимер, фосфор һәм кальций тозлары, микроэлементлар, алма һәм лимон кислоталары бар. Карабодайдагы фолий кислотасы кан әйләнешен яхшырта һәм организмга төрле авыруларга каршы торырга ярдәм итә.

Карабодай ярмасы диетик үзлекләргә дә ия. Ул организмдагы зарарлы матдәләрне чыгара. Шикәр авырулы һәм артык таза кешеләргә карабодай белән тукланырга киңәш итәләр. Ул канга бик яхшы тәэсир итә, кан тамырларын ныгыта, нерв системасына уңай йогынты ясый, организмда матдәләр алмашын яхшырта. Аны ашказаны, ашказаны асты бизе һәм эчәк авырулары булганда да кулланалар.

Карабодайдан ниләр генә пешермиләр. Әйтик, сөттә пешкән карабодайга акмай да өстәп җибәрсәң, менә дигән тәмле ботка булачак. Аны кыздырылган суган, бавыр, яки гөмбә белән дә әзерләргә мөмкин.

Мисал өчен Апас районының Чирмешән авылында кунак сые буларак зур итеп карабодай бәлеше пешерү киң таралган. Мондый бәлешне кунак-төшем булганда, балага исем кушу, өйгә Коръән укыту, әрвахларны искә алу кебек йола ашларына әзерлиләр икән. Билгеле, аны бер сәбәпсез, аш төрләндерү максатыннан әзерләргә дә мөмкин.

Бу очракта бәлеш эчлеге буларак әзерләнә торган ярма да, камыры да үзенә аерым бер игътибар сорый.

Мондый бәлеш күп итеп суган турап, май салып ит белән дә, итсез дә пешерелә. Бүген сезгә татлы бәлеш тәкъдим итәбез.

КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

Бер зур бәлеш өчен 3 стакан ярма алабыз. 1 стакан карабодай ярмасына 2 стакан су алына.

Камыр өчен:
1 йомырка;
2 аш кашыгы көнбагыш мае;
200 г катык яки кефир;
1–2 аш кашыгы каймак;
ярты чәй калагы тоз;
2 аш кашыгы шикәр комы;
ярты чәй калагы сода кирәк була.





1. Ярманы кайнап торган суга салабыз һәм аз гына пешереп алабыз. Суга тоз, шикәр, аз гына май салабыз. Су ярмадан өч бармак өстәрәк булырга тиеш. Су кайный башлагач, ярма таралып китмәсен өчен кәстрүлнең капкачын ябып, өстен зур сөлге белән каплап куябыз, шунда ул таралмыйча гына парлана.





2. Тирән савытка каймакны, йомыркаларны, кефирны, үсемлек маен һәм эретелгән акмайны, тозны салып болгатабыз. Уксус белән сүндерелгән соданы өстибез.

Шулар өстенә акрын гына или-или онны салып каты итми генә камыр басабыз.







3. Камырны, шар рәвешенә китереп, берникадәр вакытка сөлге белән каплап куябыз. Камырны бер зур, бер кечкенә кисәккә бүләбез.

Зур кисәкне юка итеп җәеп, майланган табага салабыз. Таба кырыйлары камырны кисмәсен өчен, табаны сөлге яки чүпрәк белән әйләндереп алабыз.





4. Камырны майлыйбыз, өстенә аз гына шикәр комы сибәбез; кул астында корт (кызыл эремчек) булса, аны да салырга була. Ул ризыкка үзенчәлекле тәм бирә.

Шуннан соң карабодай ярмасы салабыз, аз гына май һәм шикәр өстибез, кабат ярма салабыз, тагын май һәм шикәр комы өстибез.



5. Калган камыр кисәген уклау белән җәеп, бәлешнең өстен каплыйбыз. Бизәгәннән соң, йомырка сарысы белән майлыйбыз, өстеннән шикәр пудрасы сибеп, духовкага куябыз.




6. Бәлеш 40–45 минут эчендә пешеп чыга. Әзер бәлешнең капкачын ачып, эретелгән акмай сибеп табынга бирәбез.

Ашларыгыз тәмле булсын!

Автор фотолары

Бергәләп бизибез!



Истәлекле даталар
2026

ОКТЯБРЬ

1 октябрь

Галим, шагыйрь, ветеринария фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рифат Җамалетдин улы Корбановка 75 яшь (1951).

3 октябрь

Шагыйрә, педагог, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Сажидә Гаделша кызы Сөләймановаңың тууына 100 ел (1926–1980).

5 октябрь

Актёр, Татарстан Республикасының халык артисты Нуретдин Гыйлемхан улы Нәҗмиевкә 80 яшь (1946).

8 октябрь

Шагыйрь, прозаик, публицист, Татарстанның халык язучысы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марсель Баян улы Галиевкә 80 яшь (1946).

14 октябрь

Музыка белгече, педагог, сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Тәнзилә Габдрахман кызы Алмазовага 75 яшь (1951).

18 октябрь

Шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, журналист һәм тәрҗемәче, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Рәис улы Бохараевның тууына 75 ел (1951–2012).

21 октябрь

Режиссёр, педагог, ТАССР һәм РФның атказанган сәнгать эшлеклесе Илдус Нәсыйх улы Зиннуровка 80 яшь (1946).

29 октябрь

График, китап рәссамы, Халыкара «Китап сәнгате» күргәзмәсендә катнашкан (Париж, 1931) Фаикъ Шакирҗан улы Таһировның тууына 120 ел (1906–1978).

НОЯБРЬ

1 ноябрь

Актриса, җырчы, композитор, ТАССРның халык артисты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Сара Гариф кызы Садыйкованың тууына 120 ел (1906–1986).

2 ноябрь

Театр рәссамы, ТАССРның халык рәссамы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның атказанган рәссамы Мәэмүн Гали улы Сутюшевның тууына 120 ел (1906–1989).

6 ноябрь

Музыка белгече, педагог, сәнгать фәннәре кандидаты, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Чулпан Нәкыйп кызы Бәхтиярованың тууына 100 ел (1926–2013).

10 ноябрь

Балет артисты, педагог, профессор, ТАССРның халык артисты Наил Сәрвәр улы Сәрвәровның тууына 80 ел (1946–2021).

22 ноябрь

Балет артисткасы, балетмейстер, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле баш балетмейстеры, ТАССРның халык артисткасы Раилә Мөхәммәтхан кызы Гариповага 80 яшь (1946).

25 ноябрь

График, каллиграф, рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе һәм халык рәссамы Рушан Галәветдин улы Шәмсетдиновка 80 яшь (1946).

ДЕКАБРЬ

1 декабрь

Тел белгече, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Фәһимә Миргали кызы Хисамованың тууына 90 ел (1936–2018).

15 декабрь

Актёр, Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты Нуриәхмәт Вәлиәхмәт улы Сафинга 80 яшь (1946).

21 декабрь

Татарстан Китап палатасы төзелүгә 100 ел (1926).

22 декабрь

График, рәссам, китап бизәүче, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең атказанган рәссамы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Григорий Львович Эйдиновка 80 яшь (1946).

26 декабрь

Язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Әхәт Хафизулла улы Сафиуллинга 90 яшь (1936).

Кадерле укучыларыбыз!
2026 елның икенче ярты еллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

Индексыбыз – ПА 183
Өч айга язылу бәясе – 468 сум 51 тиен
Ярты елга язылу бәясе – 937 сум 02 тиен

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!